БЕЛЕМ БӘЯСЕ

Хезмәт хакы арту турындагы хәбәр укытучыларны ни дәрәҗәдә сөендергән?

> 6

ЛАЕКЛЫ ЯЛ

Россия Пенсия фондының Татарстан буенча бүлеге белгечләре пенсия турындагы сорауларга ачыклык кертте

> 7

РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛА:

«Татарга татардан башка беркем дә ярдәм итмәячәк»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 184 (28766) | Җомга | 17 декабрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

БӘРӘКӘТЛЕ ТОРМЫШ

АВЫЛ КЕШЕСЕ ЭШНЕ ДӘ, АШНЫ ДА ҮЗЕ ТАБАРГА ТЫРЫША

Кемдер сөт сатып көн итә, кемдер себерке бәйли, кемдер яшелчә үстереп табыш ала, ә кемдер мендәрләр ясаудан файда күрә. Авыл халкы үзеннән арткан продукцияне кайда һәм ничек сата? Шәхси хуҗалыкларда үскән, тәрбияләнгән мал-туар, кош-корттан, җиләк-җимештән, кул хезмәтеннән күпме табыш алырга мөмкин? Тырыш авыл халкыннан әнә шул хакта белештек.

> 5

Ишетми калмагыз

Теләсә кем җыя алмаячак

Хәйрия эшчәнлегенә хокукы булмаган кешеләр урнаштырган тартмалар ярдәмендә акча җыйган өчен штраф салачаклар. Дәүләт Думасы шул хактагы закон проектын соңгы укылышта кабул иткән. Хәзер Административ хокук бозулар турында Россия кодексына төзәтмәләр кертелә. Хәйрия тартмасы ярдәмендә акча җыю яки тартма урнаштыру «күп булмаган күләмдә акча урлау» (2,5 мең сумнан артып китмәгән күләмдә) дип саналачак. Гади кешеләр өчен штраф күләме, тартманы конфискацияләп, җыелган акчадан биш тапкыр артыграк күләмдә (әмма 3 мең сумнан ким түгел) тәшкил итәчәк. Шулай ук аларны 10–15 тәүлеккә кулга алу, 120 сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләргә җәлеп итү билгеләнергә мөмкин. Юридик затларга, тартманы конфискацияләп, 20 меңнән 50 мең сумга кадәр штрафлар кертелә.

Баланы да аямый

Быел Татарстанда янгыннарда һәлак булган балалар саны узган елдагы белән чагыштырганда ике тапкыр күбрәк. Янгын күзәтчелеге буенча баш дәүләт инспекторы Максим Трущин шулай дип белдерде. Аның әйтүенчә, агымдагы елда республикада биш меңнән артыграк янгын очрагы теркәлгән. Фаҗигадә 164 кешенең гомере өзелгән. «Янгын чыгу сәбәпле балаларның һәлак булуы, җәрәхәтләнүенә бәйле коточкыч саннарга игътибар иттерәсем килә. Ел башыннан бирле янгында 6 бала һәлак булды, 32се җәрәхәтләнде. Узган елда 3 баланың гомере өзелгән иде», – диган ул. Аның әйтүенчә, кайбер очракларда фаҗига сәбәбе ата-ананың ваемсызлыгына бәйле. Әйтик, 10 декабрьдә Казанның Әмирхан урамындагы йортның бер фатирында чыккан янгында 5 һәм 7 яшьлек ике сабый аздан гына һәлак булмыйча калган. Соңыннан ачыкланганча, әниләре аларны, ялгыз калдырып, кибеткә киткән. Сабыйлар шул арада кухня плитәсендә сөлгегә ут кабызып, аны диванга ыргыткан.

Өметләр зурдан

Казан шәһәре Думасы 2030 елга кадәр башкаланың социаль-икътисади стратегиясенә төзәтмәләр кабул иткән. Шушы чорга кадәр уртача гомер озынлыгын 80 яшькә җиткерү күздә тотыла. Депутатлар кабул иткән төзәтмәләр проекты буенча эшсезлек дәрәҗәсе 0,55 процентка калырга тиеш. Шул ук вакытта 2020 елда пандемия килеп чыгу сәбәпле, бу күрсәткеч шул 0,55 проценттан 2,66 процентка җиткән. Казанда спорт белән шөгыльләнүчеләрнең өлешен – 75, электрон рәвештәге дәүләт (муниципаль) хезмәтләре өлешен – 95 процентка (хәзер 75%), җан башына керем күләмен 48,6 мең сумнан 71,2 мең сумга, уртача хезмәт хакын 45,2 мең сумнан 74 мең сумга җиткерү, фәкыйрьлек дәрәҗәсен 4 проценттан 1,7 процентка калдыру планлаштырыла.

Районнарда ни хәлләр?

Тукай

Районда «Игелек кыл» хәйрия марафоны узды. Быел ул дүртенче тапкыр оештырылды. Марафон барышында хәйриячеләр ярдәме белән барлыгы 2 миллион 800 мең сумнан артык акча җыелды. Шушы көннәрдә башкалар кайгысына битараф калмый торган, сизгер күңелле, шәфкатьле кешеләр «Энергетик» мәдәният йортына җыелды. Авыр тормыш сынавы кичергән, язмыш тарафыннан рәнҗетелгән, бәхетсезлеккә юлыгып, сәламәтлекләрен югалткан райондашларга ярдәм кулы сузды. Җыелган акча 2022 елда ярдәмгә мохтаҗ булган физик мөмкинлекләре чикле кешеләрнең авыр хәлен җиңеләйтергә тотылачак. Махсус комиссия утырышы һәр мөрәҗәгать буенча карар кабул итәчәк.
(«Якты юл»)

Азнакай

Азнакай яшьләр коллектив радиостанциясендә шөгыльләнүче балалар космонавтлар белән аралашты. Әлеге чара «Татнефть» компаниясе ярдәме белән оештырылган. Ун минутлык элемтә барышында Россия космонавтлары Антон Шкаплеров һәм Петр Дубров балаларны кызыксындырган сорауларга җавап бирделәр. Район Советы аппараты җитәкчесе Айдар Хәлиуллин исә космонавтларны Азнакайга чакырды.
(«Маяк»)

Түбән Кама

Киләсе елда шәһәр һәм районда 111 торак йортны ремонтлау планлаштырыла. Капиталь ремонт программасына 800 миллион сумнан артык акча бүлеп бирелгән. Торак йортларда лифт җиһазларын алыштыру, җылыту, кайнар һәм салкын су белән тәэмин итү, су бүлү, электр белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау, түбә-диварларны төзекләндерү планлаштырыла. Юлларны карап тоту һәм ремонтлау өчен исә 128 миллион сум акча бүлеп биреләчәк.
(«e-nkama.ru»)

Кайбыч

Борындыкта модульле фельдшер-акушерлык пункты ачылды. «Бу пунктка авырып түгел, күбрәк профилактика максатында гына килергә язсын», – диде ачылу тантанасында район башлыгы Альберт Рәхмәтуллин. Киләсе елга шундый ук ФАПны Чүти авылында төзергә җыеналар.
(«Кайбыч таңнары»)

Чаллы

Җәмигъ мәчетендә ике зур манараны төзергә керештеләр. Моның өчен мең кубометрдан артык бетон файдаланылачак. Ике кечкенә гөмбәзгә дә заказ бирелгән. Гомумән алганда, проект буенча алар бишәү була. Гөмбәзләрне 2022 елның язына урнаштырырга җыеналар.
(«Челнинские известия»)

КИТЕРЕП БИРГӘННЕ КӨТӘРГӘМЕ?

ТАТАРСТАН СӘНӘГАТЬ ПРЕДПРИЯТИЕЛӘРЕНЕҢ 70 ПРОЦЕНТЫ КАДРЛАР КЫТЛЫГЫ КИЧЕРӘ

Эше бар – эшләүчесе юк. Татарстандагы сәнәгать оешмалары эшче кулларга кытлык кичерә. Эшләүчесе булмагач, иң зур предприятиеләр дә саллы гына контрактлардан баш тартырга мәҗбүр. Бу кискен мәсьәлә турында Татарстан Президенты каршындагы Куркынычсызлык советы утырышында сөйләштеләр.

tatarstan.ru

Рөстәм Миңнеханов проблеманың җитди булуын яшермәде. «Без кризиста. Вазгыятьне үзгәртергә кирәк. Сүз белән генә күпкә ирешә алмаячакбыз. Катгый, бәлки, популяр булмаган чаралар кирәктер, әмма без аларны эшләргә тиеш. Эшче көчләр булмаса, республиканың икътисади потенциалы үсмәячәк. Башкасын безгә беркем дә китереп бирмәячәк», – диде ул.

Эшче куллар ник юк? Сәбәпләр исемлеге озын: монда коронавирус пандемиясе дә, демографиягә бәйле вазгыять тә, читтән торып эшләүне кулай күрү, мигрантларның китүе дә керә. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов исә кадрлар кытлыгының бер сәбәбе булып, яңа гына мәктәпне тәмамлаган яшьләрнең квалификациясенә карата таләпләрнең артуы, шулай ук яшь буынның зур хезмәт хакы алырлык эзерлеге булмау тора дип саный. «Кытлык 40 процентка артты һәм бу күрсәткеч 27,7 мең кеше тәшкил итә. Эшче куллар аеруча машина төзелеше тармагында җитми», – диде республика җитәкчесе.

Мәсьәләне хәл итүнең иң гади ысулы – хезмәт хакын арттыру дияр идең дә, бу гына ярдәм итмәячәк. Президент әйтүенчә, белгечләргә ихтыяҗ белән сәнәгать тармагындагы икътисади мөмкинлекләрнең балансы булырга тиеш.

– Без эшче кешеләрне кайдан алачакбыз? Әйтик, эретеп ябыштыручыны? Ихтыяҗны ничек капларбыз? Барысы да хезмәт хакын гына көтеп утырамы? Юк, кем эш рәтен белә, ул эшли. Бу – квалификация мәсьәләсе. Иң мөһиме – яшьләрнең укырга теләве. Без яхшы, югары квалификацияле белгечләр әзерләргә тиеш, – дигән фикердә Рөстәм Миңнеханов. Кыскасы, белгечләрнең акыллы гына түгел, оста куллы булуы да мөһим. – Бездә бик күп уку йортлары бар, укытабыз, укытабыз, ахыр чиктә, бу кешеләр кайда соң?

Республика икътисадында 2 млн кеше мәшгуль, шуларның 470 меңнән артыгы сәнәгать һәм сәүдә тармакларында эшли. Татарстанның сәнәгать һәм сәүдә министры Альберт Кәримов әйтүенчә, зур предприятиеләр 11 меңләп кешегә ихтыяҗ кичерә.

– Без кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча предприятиеләр арасында сораштыру уздырдык, 200 меңнән артык кешене эш белән тәэмин иткән 110 компания белән сөйләштек. Предприятиеләрнең 70 процентында – кадрлар кытлыгы. КамАЗ, Горбунов исемендәге авиация заводы, «Позис» кебек предприятиеләргә хезмәткәрләр кирәк. Эшче һөнәрләр арасында слесарь, электромонтер, машинист, токарь, сәнәгать операторы, эретеп ябыштыручы, лаборант, станоклар көйләүче һәм башкаларга ихтыяҗ зур, – диде ул үз чыгышында.

Мәсьәләне хәл итү өчен, яшь белгечләргә фатир бирү, ресурс үзәкләрен тәртипкә китерү, күрше төбәкләрдән һәм башка илләрдән гастарбайтерларны активрак җәлеп итү кебек тәкъдимнәр яңгырады.

САН

Татарстан хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы фаразларына караганда, 2022 – 2028 елларга урта белемгә ия булган эшчеләргә ихтыяҗ – 22, ә югары белемле хезмәткәрләргә ихтыяҗ 30 процентка артачак.
2021 елның гыйнвар – октябрь айларында республиканың сәнәгать җитештерүе күләме 106,8 процентка җиткән.

ҺӘР АГАЧ ИСӘПТӘ

Урман хуҗалыгы

Быел Татарстан урманнарында 19 янгын очрагы теркәлгән. Былтыргыдан ике мәртәбә күбрәк бу. Алардан 6,4 миллион сум зыян килгән. Бу хакта «Татар-информ»да узган матбугат очрашуында республиканың урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров сөйләде.

– Быел катлаулы ел булды. Республикада янгыннар 210 гектар мәйданда урманга зыян салды. Җиде очракта ут махсус саклана торган урыннарда – «Түбән Кама» һәм «Идел-Чулман» тыюлыгында чыкты, – ди министр. – Шул сәбәпле, Татарстанда биш тапкыр урманнарга керүне тыеп торырга туры килде. Эссе көннәр булгач, халыкны урманга кертмәскә тырыштык.

Министр әйтүенчә, республика урманчыларының ныклы әзерлеге аркасында утны вакытында сүндерә алганнар. Татарстанда урман янгыннарын сүндерү өчен II типтагы – 20 һәм III типтагы 5 станция эшли. Бу эштә заманча технологияләр дә ярдәмгә килә.

– Урманнарны саклау «Экология» илкүләм проектының «Татарстанда урманнарны саклау» төбәк проекты тормышка ашырыла. Быел әлеге проект буенча башкарылган эшләр өчен федераль бюджеттан 200,5 миллион сум акча бүлеп бирелде, – ди министр. – Урманнарны яңарту, янгыннардан саклау буенча күп эш башкарыла. Урман хуҗалыгына кирәкле техника паркларын яңарту бигрәк тә урынлы булды.

Министр әйтүенчә, урмандагы һәр агач исәптә. Язын утыртканны көзен тагын бер кат карап чыгалар. Үсеп китмәсә, яңасына алыштыралар. Равил Кузюров әйтүенчә, бездә үз климатыбызга яраклы агачлар утыртыла һәм күп очракта алар тернәкләнеп китә икән. Бездә чыршы, нарат, каен, имән агачлары шаулап үсә.

Быел Яңа елга чыршылар сатылачакмы икәнне дә сорадык.

– Теләгән кеше аны питомниклардан сатып алырга мөмкин. Елдан-ел чыршыга ихтыяҗ кими. Шуны истә тотып, без агачларны күп кисмибез. Урманчылыкларның да чыршы сатасы килми. Быел бары тик 7 генә урманчылык чыршы сатарга теләк белдерде, – ди министр. – Мин үзем дә чыршы кисмәү яклы. Бәйрәмгә ясалма чыршы бизәдек. Үзең үстергән агачны кисүне бер дә дөрес түгел дип саныйм. Матур булып үсеп утырганына соклану рәхәтрәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин «Игелекле Татарстан» республика бәйгесендә җиңүчеләрне бүләкләү тантанасында катнашты. «Россиядә һәм Татарстанда һәрвакыт мохтаҗларга ярдәм итү оештырылды. Әмма хәзер ул максатчан юнәлеш ала. Яшьләрнең игелек кылырга омтылуына мин бик шат, чөнки әлеге эш яшь буынны тәрбияләү дә булып тора. Сезнең хезмәтегезне югары бәялибез һәм һәрьяклап ярдәм күрсәтәчәкбез», – диде ул волонтерларга. Бәйгенең гран-при иясе булып Тимирясов исемендәге Казан инновацион университеты студенты Лиана Фәйзуллина табылды. «Бу – безнең уртак җиңү. Безнең һәркайсыбыз республиканың волонтерлык хәрәкәтен үстерүгә зур өлеш кертә. Башкаларга ярдәм итү мөмкинлегем булган өчен әти-әниемә, үз командама зур рәхмәт», – диде ул. Чарада төрле юнәлешләр буенча иң яхшы волонтерларны сайладылар. Сүз уңаеннан, бүген республикада үзирекләләр хәрәкәтендә 90 меңгә якын кеше катнаша.

ЕЛ ТӘМАМЛАНА – ЭШ БЕТМИ

Татарстанда милләтара бердәмлек юнәлешендә алга таба да эш алып барылачак. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин «Татарстан – Яңа гасыр» хәрәкәте утырышында шулай дип белдерде.

Парламент башлыгы сүзләренә караганда, Татарстанның күпмилләтле халкы узып баручы 2021 елның Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителүен шатланып кабул иткән. Бу уңайдан республикада төрле дәрәҗәдәге күпсанлы чаралар оештырылуын да искәртте ул. «Әлеге елга әзерләнү һәм оештыру өчен республика оештыру комитеты булдырылды. 150 пункттан торган чаралар планы расланды», – ди Фәрит Мөхәммәтшин.

Бүген Татарстанда 173 милләт вәкиле яши. «Халыкның зурысы, кечесе булмый, бай мәдәнияте, тел, йола һәм гореф-гадәтләр хәзинәсенә ия халыклар гына була. Бу безнең республикада Татарстан җитәкчелеге, дәүләт органнары һәм муниципаль хакимият тарафыннан алып барылган милли сәясәткә туры килә. Уртак йортыбыз Татарстанның барлык халыклар өчен дә куркынычсыз һәм уңайлы булуы мөһим», – диде Дәүләт Советы Рәисе үз чыгышында.

Берочтан хәрәкәт активистларына эпидемия чорында җаваплы эш алып барулары, балалар һәм яшьләрне рухи-әхлакый тәрбияләүгә өлеш кертүләре өчен рәхмәт сүзләре дә җиткерде. Фәрит Мөхәммәтшин аларга урыннарда да эшне көчәйтергә кушты. «Бүлмәдә генә утырырга ярамый, вакыйгалар үзегездә, үзегезнең шәһәр, район, авылларыгызның иҗтимагый тормышында кайнарга кирәк», – диде ул.

Фәрит Мөхәммәтшин алда җәмгыятьне берләштерү бурычы торганлыгын да искәртте. «Бу эш алга таба да дәвам итәчәк. Беркемне дә иҗтимагый эш белән шөгыльләнергә мәҗбүр итеп булмый. Безнең иҗтимагый оешмада кешеләр йөрәк кушуы буенча катнаша, үз районнары һәм анда яшәүчеләрнең проблемаларын хәл итү өчен тырышалар. Бу эшчәнлекнең әһәмияте бәяләп бетергесез. Ул безне берләштерә», – дип искәртте парламент башлыгы.

АВЫЛЛАР ДА, «ЗАВКЛУБ»ЛАР ДА КАРТАЯ

ТР Дәүләт Советында

Парламентның Мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты бу атнада бик җитди мәсьәләләр карады. Мәдәният өлкәсендә «кадрлар потенциалы үсеше» хакында иде алар. «Потенция» – латин сүзе, безнеңчә, «мөмкинлекләр» була инде.

Бер уйлаганда, мөмкинлекләр җитәрлек кебек. Мәдәният министры Ирада Әюпова чыгышыннан аңлашылганча, бездә мәдәният учреждениеләре җитәрлек. Татарстанда 173 музей, 18 театр, 19 концерт оешмасы, 2 филармония, 2 цирк, 1510 китапханә, 1917 клуб, 42 кинотеатр бар. Шуның өстенә һөнәри белем бирүче 9 оешма һәм өстәмә белем бирүче тагын 106 оешма бар икән. Җырда җырланганча, «уйнап-көлеп, җырлап-биеп» кенә яшисе инде. Мәдәният өлкәсендә 22773 кеше эшли икән. Шуларның 16522се – хатын-кыз, ирләр – 6251. Без тормышыбыз тоткалары гүзәл затлар булуына күнегеп барабыз инде. Ирләр мәдәниятка хезмәткә ник йөгермиләр икән? Утырышта бу хакта тәгаен генә сүз чыкмады, әмма мәдәният өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакы түбән булуына ишарә ясалды. Министр әйтүенчә, уртача хезмәт хакы 37,8 мең сум икән. Уртача сан – уртача сан инде ул, эшнең асылын төгәл күзалларга ярдәм итми. Минем, мәсәлән, авыл клубларында, мәдәният йортларында эшләүчеләрнең ярты ставкада «утырулары», 13–15 мең сум хезмәт хакы алулары турында ишеткәнем бар. Һәм, иң кызганычы, «завклуб»ларның кайберләре – мөдир дә, җыештыручы да, сәнгать җитәкчесе дә. Сайлау вакытында алар – «ялкынлы агитатор»лар да әле.

Тагын берничә сан китерик. Мәдәният өлкәсендә эшләүчеләрнең 50,17 проценты югары белемле, 29,2% махсус урта белемле, калганнары – Ходай талант биргән кешеләр. Һәм рәсми мәгълүматлар буенча, авыл белән бергә «завклуб»лар да картая икән. Гомумән, мәдәният өлкәсендә эшләүчеләрнең 68 проценты 40 яшьтән узган, диделәр.

Күбрәк авыл турында язарга омтылуыбыз аңлашыладыр. Авыл – татарны, гореф-гадәт, йолаларны, мәдәни-рухи асылыбызны саклаучы урын. Шуңа күрә мәдәният белгечләренең, бигрәк тә яшьләрнең авылга кайтырга, ашкынып тормавы күңелне борчый. Комитет утырышы карарында Мәдәният министрлыгына муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыклары белән бергәләшеп мәдәният оешмалары өчен кадрлар әзерләүне камилләштерү кирәклеге турында язылган үзе. Әмма бу «сөйләштек тә таралыштык»ка гына әйләнеп калмас микән дигән шик тә туган иде. Утырышта катнашкан җитәкчеләрнең берсе – Дәүсовет Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов шикләрне таратты үзе. Әйткәннәрен сүзгә-сүз язмыйм, асылы болайрак: утырышта өстәгеләр генә сөйләде, күтәрелгән мәсьәләләрне җиргә төшеп, урынга барып җентекләп өйрәнү кирәк. Бу яктан алар комитет рәисе Айрат Зарипов белән бер сүздә иделәр. Утырышта күтәрелгән проблемаларны төптән өйрәнү һәм хәл итү юлларын тәкъдим итү өчен эш төркеме төзү кирәклеген әйттеләр. Ә проблемалар хәттин ашкан. Мәсәлән, профильле уку йортлары, аерым алганда, Н.Фешин исемендәге сәнгать училищесын тәмамлаучыларның 42,5 проценты гына үз белгечлекләре буенча эшкә урнаша. Укуларын дәвам итү өчен Мәскәүгә, Петербургка киткәннәр Казанга кире кайтырга бик ашкынып тормый. Ни өчен? Киләсе елга мәдәният өлкәсендә эшләү өчен 300 белгеч җитми, диделәр. Янә: «Ни өчен?» – диясе килә.

Инде килеп, Ирада Әюпова әйтүенчә, «мәдәният» дигән сүзне бик примитив аңларга ярамый. Бүген әлеге өлкәдә яңадан-яңа белгечлекләр барлыкка килә, яңа

tatarstan.ru

технология үтеп керә. Димәк, без заман чакыруына җавап бирергә әзер булырга тиеш. Казан дәүләт консерваториясе ректоры вазыйфаларын башкаручы Вадим Дулат-Алеев, кадрлар әзерләү системасы турында җитди уйланырга кирәк, диде. «Бездә мәдәният өлкәсендә эшләргә теләгәннәр өчен өч баскычлы белем бирү системасы бар. Ә аннан соң нишләргә? Әлеге яшьләрне хезмәт базарында ни көтә?» – диде ул. Сәнгать училищесы директоры Ольга Гыйльметдинова: «Сәнгати белем бирү хәзер бик ансат түгел, ул социаль-икътисади организм кебек», – дигән иде. Шушы организм яшәсен өчен нишләргә?

Без утырышта әйтелгән кайбер фикерләргә генә тукталдык, берсен тартсаң, икенчесе эяреп чыга. Кадрлар турында сүз күп булды. Ирексездән, совет чоры искә төште. Ул заманнарда максатчан укыту, юллама белән эшкә урнашу дигәннәре бар иде. Яшь белгечләргә эшләү, яшәү өчен шартлар да тудырылды. Үткәннәрдән яхшы якларны кире кайтару зыян итмәс иде.

Бүген: «Авылда кеше беткәч, клуб нәрсәгә иде ул?» – диючеләр дә бар. Моңа ничек җавап бирергә соң? Заманында оптимальләштерү шаукымы белән кайбер авылларда клуб ишекләренә йозак салдылар инде. Бер беткәнне кире кайтару айһай кыен, хәтта мөмкин түгел эш.

Арчада яшәгән каләмдәшем Ильяс Фәттахов сөйләгәннәре искә төште әле. Бер елны Арчага Америкада яшәүче татарлар кайткан, Ильяс аларны озатып йөргән. Кардәшләребез авыл клубларын күреп сокланганнар, шатланганнар ди. «Безнең дә шундый йортыбыз бар, җыелышып сөйләшеп, җырлашып утырабыз, күңел ачабыз», – дигәннәр ди. Ул йорт клуб дип аталмый, әмма бар икән бит клуб вазыйфасын башкарган йорт. Иң алга киткән илләрнең берсе саналган Америкага ни хаҗәтемә кирәк икән мондый йортлар? Кыскасы, уйласаң, уелып китәрлекләр бар әле мәдәният өлкәсендә. Димәк, сөйләшүгә нокта куярга да иртәрәк.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Әйтеп кенә бактым

Оялу

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Эш буенча безгә хакимиятнең төрле тармаклары уздырган утырыш-җыелышларда еш катнашырга туры килә. Мин, гадәттә, чыгыш ясаучы татарларның кайсы телдә сөйләвенә игътибар итәм. Кызганыч, ана телен санга сугучылар сирәк. Хакимият әһелләре, күрәсең, рәсми чыгышлар бары тик урыс телендә булырга тиеш дип саный.

Аларны гаепләргә җирлек тә юк, аптыраганнан дәүләт телләре турында законны ни пычагыма кабул иттек соң, дип уйлап куясың. Кайбер җитәкче иптәшләргә, депутатларга: «Ни өчен татарча чыгыш ясамыйсыз?» – дип әйткән дә бар. Күбесе татарчасы әллә ни булмаганга ояла, уңайсызлана икән. Ә ана телен белмәүнең берниди ояты юк булып чыга. Бездә «оятсыз оялса, каты ояла» дигән әйтем бар. Аның кайчан, нинди вакыйга уңаеннан килеп чыккан икәнен белмим, әмма шәп әйтелгән. Безне шул ояулу харап итә икән бит. Ә мин тиле әллә нәрсәләр уйлап бетердем. «Ана теленнән ваз кичү – анадан ваз кичү инде ул», – дип сөйләп йөри башладым.

Күптән түгел шифаханәдә ял итеп кайттым әле. Ашау-эчү дә әйбәт, дәвалану да, табиблары да менә дигән. Әле шуларга өстәп, төрле кызыклы очрашулар да үткәрәләр. Берсенә, аккордеонын күтәреп, Валентина исемле бер ханым килде. Ветераннар советында культура-масса эшләре буенча даими комиссия рәисе икән Валентина Витальевна Данилова. Халык каршына чыгуга елмаеп җибәрде дә: «Сезнең арада татарлар да күптер», – дип, Тукайның «Туган тел» шигырен сөйләде, урысчага тәрҗемәсендә диюем. Ул да булмады: «Бу – сезнең гимн, һәрхәлдә үзем шулай кабул итәм», – дип, «Туган тел»не татарча җырлый да башлады. Урысча акценты шактый сизелсә дә оялып тормады ул, хәтта шигырьнең «И туган тел, синдә булган иң элек кыйлган догам. Ярлыкагыл дип үзем һәм әткәм-әнкәмне Ходам» дигән куплетын да төшереп калдырмады. Татарча начар белүеннән кыенсынмады. Әле тагын биш-алты җырыбызны башкарды. Аңа без дә кушылдык. Татар авылларында эшләргә туры килүен дә сөйләп, милләтебезгә югары бәя бирде Валентина Витальевна. Аның урынында татар өммәтеннән берәр җитәкче-фәлән булса, мөгаен, татарча такы-токы белүеннән оялып, урысчага күчәр иде. Чөнки андыйлар урыс телен «элита теле» саный, шуның белән оялып булса да горурлана.

Күптән түгел Россия Думасы гавами хакимият органнарын оештыру принципларына кагылышлы закон проекты өченче укылышта кабул итте. Без уңайсызлана-уңайсызлана каршы килеп маташтык – файдасы булмады. Бу закон проекты тирәсендә бүтән тавыш та куптармадык, «оятыбызга көч килер» дип шикләндек. Думага Татарстаннан сайланган депутатларның кайберләре: «Президент атамасын алыштырудан берни дә үзгәрмәс», – дигәнрәк сүзләр белән безне тынычландырырга тырышты. Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елында без әнә шундый бүләк алдык. Ярый әле татарча сөйләшүне тыю турында федераль закон юк. Хәер, аның кирәге дә шул хәтле генә, ана телен без берниди законсыз үзебез дә бетерә алабыз. Моңа мисаллар адым саен. Оялудан күлмәк итәге белән битен каплаган кеше хәлендә калмасак ярый инде.

КАРАҢГЫЛЫК ТАҢ АЛДЫННАН КӨЧӘЯ

Ел саен декабрь аенда без алдагы елга фаразлар язабыз. Юк, без киләчәктәниләр буласын алдан белә алмыйбыз, әлбәттә, чөнки андый сәләт адәм балаларына бирелмәгән. Әмма вакыйгаларның үсеш мантыйгы һәм математик исәпләүләр ярдәмендә тормышның кай юнәлештә үсәчәген чамалый алабыз.

Соңгы ике-өч елда автор фаразларны ике тапкыр яза: берсе – редакция өчен генә, икенчесе киң аудиториягә тәкъдим ителә. 2021 елга фаразны «Яңа фаразлар искесеннән яхшыракмы?» дип атаган һәм язмада дөньякүләм хәлләрнең катлауланасын әйткән идек. Ел ахырында күзаллауларның 200 процентка тормышка ашуын күрдек. Мәйданда – без бөтенләй уйламаган хәлләр. Чикләүләр көчәйде, пандемиянең «дулкын»нары без уйлаганга караганда да дәһшәтлерәк булып чыкты. Бәяләр бөтенләй чиктән ычкынды, кесә хәле начарайды. Планетада зур сугыш чыгу куркынычы артты. Державалар бер-берсеннән ерак ике ноктада Бөтендөнья сугышының төенен төйни: Кытай Тайване һәм Украина тирәсендә хәләр катлаулана.

Әле яңа гына АКШның урта һәм кече ераклыкка оча торган ракеталарын Европада урнаштырачагы мәгълүм булды. 1985 елларда янкиларның андый ракеталары Германиядә бар иде һәм алар Мәскәүгә һәм СССРның башка шәһәрләренә төбәлгән иде. «Першинг» дип аталган ул канатлы ракеталар үзләренең санаулы минутлар эчендә безгә килеп җитә алулары белән зур куркыныч тудыра иде. Бүген янкилар Россиянең борын төбенә генә Precision Strike Missile дип аталган яңа баллистик ракеталар китерергә җыена. Аңлашыла инде: болары тагын да зуррак куркыныч тудыра. Дөрес, каршы як үз ракеталарына атом-төш очлыклары куймаска вәгъдә бирә.

2021 елда зур бер тарихи борылыш булды: Америка гаскәрләре хурлыклы рәвештә Әфганстаннан качты. Берничә дистә миллиард долларлык хәрби техника «Талибан»* кулына калды, илдә идарәгә дә шулар килде. Әле менә берничә көн элек кенә Байден – Путин телекүпере булды бит. Менә шуның алдыннан Трамп – АКШның элеккеге Президенты: «Путин Байденнан курыкмый, чөнки Әфганстаннан безнең ничек качуыбызны күрде», – дип чыгыш ясады. Әлегә Әфганстанда хәл катлаулы, әмма, бердән, ул тотрыклануга таба бара, икенчедән, күпчелек державалар акрын-акрын «Талибан» белән хезмәттәшлек итү ягына таба атлыйлар. Зур тарихи әһәмияткә ия күренеш бу, чөнки дөньяның иң куәтле державасының әйбәт кенә итеп ияк төбенә суктылар һәм ул үз ихтыярын башкаларга көчләп тагу мөмкин түгеллеген аңлый башлады. Бу юллар язылу алдыннан гына Кытайның югары җитәкчелеге: «Кушма Штатлар демократия һәм кеше хокуклары сылтавы белән дөньяда ирекле хәрәкәт итә торган дәвер тәгәлләнде», – дип белдерде. Өченчедән, элекке дошманнарның сөйләшүләр өстәле янында тыныч кына утыра алуларын күрсәтеп, әфган эпопеясы бөтен кешелек дөньясына

pixabay.com

үрнәк сабак бирде. Әфганстан Үзәк Азиягә караса да, без андагы тектоник үзгәрешләрне Якын Көнчыгыштагы тарихи борылыш моментының кереш өлеше дип саныйбыз.

Алдагы елларда без, фаразлар язганда, укучылар игътибарын гел Якын Көнчыгышка юнәлтергә тырыша идек. Нәкъ менә шул төбәктән Җир шары күләмендәге мөһим үзгәрешләрнең старты бирeләчәк дип саный идек. Без үз фикеребездә калабыз, чөнки ул фаразлар тормышка ашу стадиясендә. Әмма 2022 елда, мөгаен, төп халыкара вакыйгалар Көнбатыш – Россия, Көнбатыш – Кытай яссылыгында барыр. Әгәр конфликт Көнбатыш – Кытай мәйданында көчәйсә, Россиягә Көнбатыш белән аркадашлык итәргә туры киләчәк. Учак безнең көнбатыш чикләрдә ягылса, бер дә яхшы түгел. Ике очракта да Якын Көнчыгыш Көнбатыш белән хезмәттәшлек итәчәк.

Сугыш булмаска да мөмкин. Безне бөтенләй башка нәрсәләр белән куркыта алалар. Яңа пандемия куркынычын мәйданга чыгарулары бик мөмкин. Гафу итегез, безне чит планета вәкилләре белән сугышка өзерләргә тырышу да була ала. Берниди чит планета вәкилләре дә юк, әлбәттә. Җир тирәсендә аларның кораблары да әйләнеп йөрми. Әмма хәзерге технологияләр белән кешелек җәмгыятен ышанмастай нәрсәләргә ышандыру берни дә тормый. 2021 ел ахыры вакыйгалары ничек буласын бер ел элек язсак, аны фантастикага тиңләүчеләр күп булыр иде. Әмма дөнья шәһәрләре урамнарында бүген барган хәлләр сюрреализм бит инде, башка берни дә түгел, ягъни саташулы төшкә охшаган. Безнең чынбарлык шундый.

2022 ел турында без бер нәрсәне өзеп әйтә алабыз: ул 2023 елга караганда яхшырак булачак. Вакыйгалар елдан-ел турбулентлык зонасында үстереләчәк, нык сикертәчәк барыбызны да. Әмма артка борылып карасак, без 2021 ел сикертмәләрен уңышлы гына узып килүебезне күрәбез. Бу юллар авторы, исән булса, киләсе ел ахырында да, Аллаһ теләсә, «Ватаным Татарстан» укучылары өчен 2023 ел фаразларын язар һәм 2023 елның 2024 елга караганда җиңелрәк булачагын фаразлар дип өметләнік.

Хәзер инде сикәлтәле юлда үзебезне тоту кагыйдәләрен искә төшерик. Безне рухи яктан сындырырга тырышучы кара көчләр бар һәм алар, шиксез, үз тәртипләрен бөтен дөнья күләмендә көчләп тагарга тырышачак. Караңгылык артачак. Вәләкин бер нәрсәне һәрвакыт истә тотыйк: караңгылык таң алдыннан көчәя. Тарихның борылыш мизгелендә яшәү бик авыр, әмма онытмыйк: Җир шары һәрвакыт яктылыкка таба әйләнә. Авыр елларның тезмәсе безне кешелекнең яңа таңына таба алып бара. Статистикага карасаң, 2021 ел бик авыр үтте кебек, әмма артта калган кыенлыклар булмаган да төсле. Авырлыклардан соң җиңеллек киләчәгенә ныклы ышаныч безгә 2022 елны да уңышлы үтәргә булышыр. Сикәлтәле юлны үтүнең төп кагыйдәсен аңлаткан Әбү Һөрәйрәдән тапшырылган бер хәдис бар: «Үзеңә файда китергән нәрсәдә тырышлык күрсәт, Аллаһтан ярдәм сора һәм беркайчан да бирешмә». Аллаһ илчесенең бу киңәшен тотканнар уңа һәрчакта да, тормышның бөтен чытырманлыкларын ерып чыгалар. Ул киңәшне мәшһүр Уинстон Черчилль дә үзләштергән икән. Гомер кояшы баеп барганда, ул кайчандыр үзе укыган Харроу колледжына соңгы лекциясен укырга килә. Бөек британ сәясәтчесенең зирәклеген үзләштереп калырга дип, инглизләр бөтен Англиядән колледжга җыелалар. Хәлсезләнгән Черчилль исә алкышлар астында акрын гына мөнбәргә килә дә микрофонга бер генә фраза әйтә: «Беркайчан да, беркайчан да, беркайчан да, беркайчан да бирешмәгез», – ди. Аның гомер буе җыйган зирәклегеннән торган лекциясе менә шул була. Ул хикмәтле сүзләрне күпчелек хәзер Черчилльнеке дип белә, әмма Аллаһ илчесе тулырак, мәгънәлерәк итеп әйткән. 2022 елның вакыйгалары бөтерелгәндә менә шул зирәклекне үзебезгә девиз итеп алсак, ин шәә Аллаһ, 2023 елга уңышлы аяк басарбыз. Әле ул сүзләр безгә 2023тә дә, 2024тә дә, аннан соң да кирәк булачак.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

* «Талибан» – Россиядә тыелган оешма.

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Кош сатудан – 45 мең

Чүпрәле районының Шланга авылында яшәүче Рузия Сәгъдиева ел саен кош-корт алып үстерә дә аның бер өлешен сата икән.

– Узган елларда 50шәр баш каз, 25 баш тирәсе үрдәк ала торган идек. Быел шуның яртысын гына алдык та үрдәкнең килограммын – 400, казныкын 450 сумнан саттык. Сораучыларга баш-аякларын да бирдек. Аларның бер комплектын 350 сумнан җибәрдек. Безнең якларда бәяләр бер тирәдә йөри. Аны халыкка тәкъдим итәр алдыннан башкалар белән киңәшләшеп куябыз. Каз-үрдәкләрдән тыш, быел 100 бройлер үстердек. 10–15ен үзебезгә калдырдык та калганын саттык. Анысының килограммын 300 сум итеп билгеләдек. Болардан тыш, тагын тай үстереп сатабыз. Каз мамыкларын да әрәм иткәнебез юк. Безнең якларда аларны чегәннәр җыеп йөри. Килограммына 1 мең сум бирделәр быел. Узган елларда 700–800 сумга сатып алалар иде. Сораучы булса, туганнарга, таныш-белешләргә мендәр дә ясап бүләк иткән вакытларыбыз күп, – диде ул.

Рузия Сәгъдиева әйтүенчә, аларның авылларында күпчелек халык менә шулай үзе тырышып, хәләл көчен биреп үстергән, тәрбияләгән малдан файда күрә. Җәен үзләреннән арткан җиләк-җимеш, яшелчә сатучы да бар.

– Узган ел бары тик кош-корт кына сатып, 45 мең сум акча җыйган идем. Быел санамадым. Абзарда мал, кош-корт булганда, яшәргә була әле. Файдасын бик күрәбез. Шул акчага ниндидер эшләр дә эшләү мөмкинлеге барлыкка килә. Иптәшем дә, үзем дә беркайда эшләмибез. Кош-корт саткан акчадан балаларга да өлеш чыгарабыз. Мәсәлән, студент улыбызга Ульяновскида фатир алдык. Укуын да, ипотекасын да түләп барырга әнә шул керемнәрнең ярдәме тия, – диде Рузия ханым.

«Мал асрауның файдасы бар!»

Авылда яшәүчеләрнең күпчелеге сыер асрап, шуның сөтен сатып, азмы-күпме акча эшли ала. Сөт бәясе бик түбән булмаган очракта, бәлки, күпмедер керем дә кертү мөмкинлеге бардыр. Һәрхәлдә, Әлки районы Түбән Әлки авылында гомер итеп, алты сыер асраучы Алсу Гәрәева: «Сыер тотуның файдасы бар!» – ди.

– 2011 елда ике сыердан башлаган идек. Бүген алты сыер савабыз. Бозауларның берсен генә үзебезгә иткә калдырабыз да, калганнарын сатабыз. Һәм аларның акчасын җыеп барып, ел саен ниндидер бер зур әйбер алабыз яки йортны төзекләндерәбез. Сөт акчасыннан шулай ук файда күрәбез. Җәен 30–35 мең сум чыкса, бүген 20–25 мең сум акча алып барам. Каз-үрдәкләр дә тотабыз. Гадәттә, 30 казның 15ен шулай ук сатабыз. Үрдәкләрнең дә яртысы кешегә китә, – ди ул.

Алсу Гәрәева әйтүенчә, каз-үрдәк бәяләре башкалардан аерылмый. Килограммы – 400–450 сум. Баш-аякларын 300–350 сумнан саталар.

– Безгә файда инде ул. Мин әле сыерларны бетерергә уйламыйм да. Кешеләр, сыер асрауның файдасы юк, дисә дә, без алай санамыйбыз. Бер айлык сөт акчасына печән хәстәрлибез, икенчесенекенә ашлык алып кайтабыз. Шулай булгач, начар дип әйтеп булмый, – ди хуҗабикә.

Заманында кишер дә сатканнар, тик аннан әллә ни керем булмагач, туктатканнар.

– Бакчада помидор уңган елны да үзебездән артканын сатып бардык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

БӘРӘКӘТЛЕ ТОРМЫШ

Җиләк-җимеш, яшелчәне әрәм иткәнебез юк. Авылда алты-җиде сыер асраучылар да бар. Алар да төп керемне шул маллардан ала. Чөнки авылда хезмәт хаклары аз, – диде Алсу Гәрәева.

Табыш алганчы йөгерергә кирәк

Азнакай районының Урманай авылында яшәүче ирле-хатынлы Галия һәм Зирәк Мөхәммәтшиннар менә инде шактый еллар үзләре җитештергән продукцияне сатып көн итә. Хуҗабикә хәзер пенсиядә. Ләкин эшләгән елларда да атнасына берничә тапкыр район үзәгенә барып, үз хуҗалыкларында җитештергән продукцияне сатканнар.

– Совхозның көчле, сөтнең литры 35 сум йөргән вакытлар иде ул. Алты ай дәвамында хезмәт хаклары алмаган чакларда сөтне җыеп йөрүчеләргә генә тапшыра идек әле. Шуннан соң Азнакайга барып йөри торгач, акрынлап үз сатып алучыларыбыз барлыкка килде. Хәзер инде шактый еллар бер урында сату итәбез. Ел дәвамында атнасына берничә тапкыр барабыз, – ди Галия Мөхәммәтшина.

Моңа кадәр өч сыер сауган булсалар, быел икегә генә калдырганнар. Шул өч сыерның сөтен, каймагын, катыгын, ак һәм кызыл эремчеген, кортын, маен ясап сата ул. Болардан кала, бройлер, каз-үрдәк, каз мамыгы, балан, гөлҗимеш һәм башка төрле җиләк-җимешне халык яратып ала икән. Как ясап, йон оекбашлар бәйләп саткан чаклары да булган.

– Бүген авылда сөтнең литрын 26 сумнан җыялар. Без исә шәһәрдә 70 сумнан сатабыз. Бройлерның килограммы – 280, казларныкы 500 сум тора. Урын өчен сораганнары юк. Берара андый тәртип кертмәкче булганнар иде. Соңыннан анысы да бетте. Гадәттә, алып килгән әйберләребезне сатып бетереп кайтабыз. Казларны гына барысын да берьюлы алмаска мөмкиннәр. Без үзебез ел саен 20–40 баш каз сатып алабыз. Үзебезгә дә калдырабыз, билгеле. Тозлыйм да, ыслыйм да. Ләкин анысын гаиләбез сыйланыр өчен генә эшлим, – диде ул.

Тырышып эшләгәч, файдасын да, бәрәкәтен дә күреп яшиләр Мөхәммәтшиннар.

– Файдасы бар, әлбәттә. Акчаны җыеп, зур әйберләр алдык, димәсәк тә, алган кредитларны түләп барырга җитәрлек акча кереп бара. Анысы да – зур ярдәм, сөтнең кереме начар түгел. Эшләгән вакытта да өстәмә акча керә торган урын булды ул. Ләкин файдасын күрә башлаганчы, тырышырга, йөгерергә, аяк өстендә булырга кирәк инде. Башкача булмый, – диде Галия ханым.

Булганы җитә

Арча районының Шура авылында яшәүче Рәхмәтуллиннар гаиләсе дә тырышлыкларының җимешен күрә. Алар себерке бәйли, печән үстерә, гөмбә җыеп, аны эшкәртеп саталар.

– Авыл җирендә халык бары тик үз көченә, үз тырышлыгына гына таяна ала. Булдыра алганнар мал асрап, көн күрә. Без инде икебез дә пенсиядә. Әллә ни сатып акча эшләмәсәк тә, булдыра алганча тырышабыз, – диде Кәшшаф Рәхмәтуллин. – Әле менә шушы көннәрдә генә 50 себерке сатып җибәрдек. Умарталарыбыз бар иде. Алары агуланып, үлеп бетте. Калган балларын әле дә булса ашыйбыз, сорап килүче булса, сатып та җибәрәбез. Пай җирем бар иде. Шул урынга печән чәчәбез дә шуны сатабыз. Быел 17 мең сумлык керем керттек. Үзебезнең агач ярдыру цехыбыз бар. Иптәшләр сораса, анда такта ярдырып бирәм. Безгә күп тә кирәкми инде. Булганы җитә. Яшьрәк вакытта мал асрап, шактый файдасын күрдек. Өчәр сыер асрап, шуның сөтен, бозауларын сата торган идек.

Хатыны Халидә апа да тик тормый икән. Көзен гөмбә җыя, кыяр-помидор тозлап сата.

– Әле менә 2 литр гөмбәне 600 сумнан саттым, – диде хуҗабикә. – Яратам мин гөмбә җыярга. Эшкәртергә дә рәхәт. Тозлы кыяр-помидорны да сорап килүчеләргә бирәм. Күчтәнәчкә дә күп җибәрелә. Гомумән, без бер әйберне дә бәя куеп сатканыбыз юк. Ничә сум бирә алалар, шул бәягә алып китәләр.

Суган орлыгы сатабыз

Чирмешән районының Кара Чишмә авылы халкының күпчелеге суган орлыгы сатып көн күрә. Мортазиннар гаиләсе дә ел да әнә шулай орлык сатып, акча эшли.

– Без орлыкка гомер-гомергә утырттык. Шул гадәт буенча яшибез инде. Зур бакчада да чүп үлән үстереп булмый. Вак суган чәчә торган аппарат алдык, шуның белән эшлибез, – диде Фикс Мортазина. – Орлыкны гадәттә 15–17 стакан чәчәбез. Февраль урталарында белешә башлыйлар инде. Апрельдә алып та бетерәләр. Файдасын күрәбез. Кереме булмаса, ел да мәшәкатьләнмәс идек. Килограммын 200 сумнан саттык. Әр центнер җибәргән еллар да булды. Уртача 50–60 мең сум акча эшлибез. Һава торышы уңай килгән чакларда аннан да күбрәк керем керткәнебез булды. Аннан соң без эре суган да үстереп саттык. Пенсиядә булгач, маллар тоту авыр. Шуңа күрә бакчада гына кайнашабыз. Балаларга да, үзебезгә дә җитәрлек яшелчә әзерлибез. Халыкка да әлеш чыгарабыз. Иренмичә эшләгәндә күңел булырлык табышы керми калмый инде. Тырышырга гына кирәк.

Менә шулай «Акмаса да, тама», – дип, никадәр табыш алса да, шөкер итеп яши белә авыл кешесе. Хәләл көчләрен куеп үстергән малларының, кош-кортларының, тырышлык белән тапкан табышларының бәрәкәтен күрергә язсын иде аларга.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ДАНЫ ОЛЫ – КАБЫРГАСЫ КОРЫ БУЛМАСМЫ?

КИЛӘСЕ ЕЛНЫҢ ГЫЙНВАРЫННАН УКЫТУЧЫЛАРНЫҢ ХЕЗМӘТ ХАКЫ АРТАЧАК

2022 елның 1 гыйнварыннан бюджет өлкәсендә эшләүче мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт хакы уртача 2,5 меңнән 5,5 мең сумга кадәр артачак. Сер түгел, бүген мөгаллимнәргә дәресләрне арттырып укытырга туры килә. Әлеге яңалык укытучыларны ни дәрәҗәдә сөендергән? Акча белән эше дә артмасмы?

Укытучыга нинди ярдәм бар?

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, республикада 76 меңнән артык мәгариф хезмәткәре исәпләнә. Шуларның 36 меңе – укытучылар, 22,7 меңе – тәрбиячеләр. Калганнары өстәмә белем бирүдә, урта һәм һөнәри уку йортларында хезмәт куя. Бүген тәрбиячеләрнең уртача хезмәт хакы – 31,2, укытучыларныкы – 36,7, мәктәп директорларыныкы – 55,4, бакча мөдирләренеке 36,8 мең сумны тәшкил итә. Хезмәт хакыннан тыш, укытучыларга төрле бәйгеләрдә катнашу мөмкинлеге бар. Анысы да әҗерсез түгел. «Безнең яңа укытучы» бәйгесе җиңүчеләренә өч ел дәвамында айга 8600–10000 сум акча түләнә. Укучылары бөтенроссия олимпиадаларында җиңгән, призер булган укытучыларга айга 10–40 мең сум өстәлә. «Авыл укытучысы» федераль программасы буенча авылга 11 укытучы кайткан. Башкортстаннан – 4, Кемероводан – 2, Оренбург, Киров, Чиләбе өлкәләре, Татарстан, Чувашиядән берәр укытучы Татарстан мәктәпләрендә белем бирә. Аларга берәр миллион сум акча бирелгән.

– Киләсе елдан укытучыларның хезмәт хакын арттыру турында карар кабул ителде. Бу кече тәрбиячеләргә, пешекчеләргә, техник хезмәткәрләргә, мәктәп директорлары, урынбасарларга кагыла. Уртача алганда, оклад 2,5 меңнән 5,5 мең сумга кадәр арта, – диде Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин «Инстаграм»да узган «туры элемтә» вакытында.

ФИКЕР

Светлана БАЙКЕЕВА, «Ел укытучысы – 2020» бәйгесе җиңүчесе:

Бүген югары уку йортын тәмамлап, мәктәптә бер ставкага эшләгән, стажы, квалификациясе булмаган яшь укытучы минималь хезмәт хакы ала. Әгәр ул гаилә корырга җыена икән, әти-әниләр ярдәме булмаса яки дәүләттән субсидия бирелмәсә, өстәвенә икесе дә укытучы булса, яшәргә бик авыр булачак. Хәзер педагоглар ничек тә булса яшәр өчен бердән артык ставка алырга тырыша. Бу башка мәктәпләрдә укытучылар җитмәүгә дә бәйле. Дәүләтнең мәгарифкә игътибары арту сөендерә, әлбәттә. Укытучыларның бирсә дә әлеге акчаны артык димәячәк. Әмма кибетләрдә бәяләр ел саен кыймммәтләнеп тора бит. Уртача туклану кәрҗине күпмегә төшәр һәм бу акча арту ни дәрәҗәдә үзен аклар икән? Монысы да мөһим.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Өйгә ияреп кайта торган эш

Укытучылар арасында хезмәт хакыннан риза булучылар да, шул ук вакытта канәгатьсезлек белдерүчеләр дә бар. Бигрәк тә яшь укытучылар җәл. Ирләрне дә аз акчага мәктәптә тотып булмый. Шуңа күрә башка өлкәләргә китүләренә дә аптырыйсы юк. Акча аз, өстәвенә сыйныфтагы 35әр укучыны тыңлатырга, аларның әти-әниләре белән дә уртак тел табарга кирәк. Эше дә өйгә ияреп кайта торган. Барысын да бизмәнгә салып үлчәгәч, андыйлар укытучылык эшен хупламый. Мисал өчен, Татарстанда физика, рус теле, математика, биология һәм химия укытучыларына кытлык. Мөгаллимнәрнең уртача яше – 44–45, 35 яшькә кадәрге яшь педагоглар исә – 25 процент чамасы гына.

Теләче районының бер мәктәбендә математика дәресләре укыткан Гөлинә Галимбәкова гаиләсе белән терлекчелек өлкәсендә үз эшен булдырган. Аның белән яшь укытучыларның мәктәптән китү сәбәпләре турында сөйләшеп алдык.

– Гыйнварда артачак акча күп түгел. Бу яшьләрнең хезмәт хакына әллә ни тәэсир итмәячәк. Алар болай да аз хезмәт хакы ала бит. Күпчелеге эш хакыннан канәгать булмаганга мәктәптән китә. Документ тутыру эше күп, үз фәнең белән шөгыльләнергә вакыт калмый. Күп кенә бәйгеләрдә катнашуны таләп итәләр. Анда катнашмый булмый. Ник дигәндә, хезмәт хакының баллар белән бәяләнә торган өлеше бар. Әти-әниләр һәм балалар проблемасын да әйтмичә булмый. Әти-әниләр балаларын әллә кем итеп күрә. Ә бит укымаган баладан даһи ясап булмый, – ди Гөлинә. – Яшьләрне кызыксындыру өчен акча күп кирәк. Әйтик, аена 25 мең сум ипотека түләүчеләр бар. Яшь белгеч моның кадәр акча аламы әле ул? 4–5 ел элек 15 мең сум хезмәт хакына эшләдем. Хәзер дә арткан дип әйтә алмыйм. Мин белгән 3–4 яшь укытучы башка өлкәгә күчте, декрет ялында утыручы кайберләренең кабат мәктәпкә кайтасы килми. Тормышны алып барыр өчен бу акча җитми. Бер төркемдә укыган егет: «Әгәр өйләнсәм, бу акчага гаиләне ничек туендырыйм?» – дип, эштән китте. Мин исә үземә мәктәптән кызыклырак эш таптым. Элек гаиләгә вакыт калмый иде. Хәзер бу яктан проблема юк. Мине әле дә, берничә сәгать укытырга булса да килмисеңме, дип чакыралар. Әгәр хезмәт хакы лаеклы булса, ризалашыр да идем, бәлкем. Әмма хәзер анда барып торудан файда юк. Әгәр яхшы хезмәт хакы түләнсә, мәктәпләрдә укытучыларга кытлык булмас иде.

«Мәктәпләр әбиләргә калып бара»

– Хезмәт хакының артуын көтеп торабыз. Бүген укытучыларга 1,5 ставкага эшләргә туры килә. Бу кадрлар кытлыгына бәйле. Яшьләр мәктәпкә килергә ашыкмый тормый. Бигрәк тә математика, информатика, физика фәннәре буенча укытучылар җитми. Соңгы вакытта укучыларны вузга максатчан программа буенча укырга җибәрә башладык. Классы булмаган педагог 20 мең сум ала. Өстәмә дәресләр укытса, акчасы 30 меңләп чыга. Укытучының эше күп, өенә дә ияреп кайта. Атнага 18 сәгать укыткан өчен 30 мең сум түләнсә, укытучылар риза булыр иде, минемчә. Яшь укытучылар 14не түгел, 30 меңне алса, эштән китмәсләр иде. Алар бит балаларны ярата, – диде Казанның бер мәктәбе директоры.

Мамадыш районының Усали мәктәбе укытучысы Лидия Пасыева әйтүенчә, гадәттә укытучының акчасы арта дип, алдан бик шаулыйлар да, ул әллә ни күп артмый. Күбрәк «Даны олы – кабыргасы коры» дигән мәкальдәгечә килеп чыга.

– Бу юлы тагын ничек булыр? Хезмәт хакыннан канәгать дип әйтә алмыйм. Никме? Без инде яшь укытучылар түгел, категориябез дә, стажыбыз да бар. Дәресебез дә 18 сәгатьлек бер ставка гына түгел. Шуның белән уртача 25 мең сум тирәсе акча алабыз. Бүген моны зур хезмәт хакы дип мактанып булмый, – ди Лидия Пасыева. – Ә хезмәт юлын башлаган гына кешенең акчасы бигрәк тә аз. Яшерен-батырын түгел, мәктәп әбиләргә калып бара. Бу авылда да, шәһәрдә дә шулай. Әбиләр начар укыта димим мин, һич юк. Без дә – кайчандыр укучы булган кешеләр бит. Сүз дә юк, яшь укытучыны ярата идек. Безне укытканда өлкән укытучы дип кабул иткән укытучыларыбыз яшьтә без хәзер. Яңа уку елын: «Быел мәктәпкә нинди яңа укытучы килер икән?» – дип көтә идек. Хәзерге авыл балалары ул бәхеттән мәхрүм. Без укучы булган чорда «пенсиядәге укытучы» дигән кеше юк иде. Алар яшьләре җитү белән лаеклы ялга китеп бардылар. Яшьләр ник мәктәпкә килми? Монда, әлбәттә, акча мәсьәләсе беренче урында түгел. Беренчедән, кеше вуз бетереп кенә укытучы була алмый. Ул укытучы булып туарга тиеш. Икенчедән, укытучы якланмаган, мескен хәлдә. Җитәкчеләрнең: «Әти-әниләр һәрвакыт хаклы», – дигәнен ишетеп, шаккатканым бар. Алар һәрвакыт ничек хаклы булсын инде? Эш дәверендә мәгариф бүлеге җитәкчеләренең: «Гаебең булмаса да, әти-әнидән гафу үтен!» – дип, укытучыны кыстаганнарын да күргән булды. Имеш, зурга китмәсен, имеш, җүләр белән җүләр булып булмый… Кәгазь боткасына да түземи яшь укытучы. Укучыларга кирәкмәгән регистрация, мең төрле тест, әллә нинди тавыш бирдертүләр, тегә конкурс, мондый бәйге… Тынгысызлыкка түземи яшь белгеч, китә дә бара… Өенә эше ияреп кайтмый торган, ялы ял төсле булган эш эзли ул. Шуңа күрә акча арткач, яшьләр мәктәпкә агылыр дигән ышанычым юк.

Сәрия МИФТАХОВА

Сорау – җавап

НИК ТИГЕЗ ТҮЛӘМИЛӘР?

Мин унбиш елдан артык укытучы булып эшлим. Шул ук вакытта тәрбия эшләре буенча директор урынбасары вазыйфасын да башкарам. Үз теләгем белән түгел. Ләкин ул безнең мәктәптә ставканың 25 процентын, ә укыту эшләре буенча директор урынбасарыныкы 75 процентны тәшкил итә. Ни өчен ул һәрберебезгә дә тигез түләнми? Районыбызның күп мәктәпләрендә 50 процент итеп бирелә. Шуны аңлатып бирүче юк. Минем өстә җаваплылык бик күп. Һәр атна саен акция, бик күп чаралар үткәрергә, барысына да хисап төзергә кирәк. Әти-әниләр белән эшлисе бар. Кыскача гына әйткәндә, социаль педагог, өстәмә белем бирү педагогы вазыйфасын да башкарам. Эш сәгате беткәннән соң районга җыелышка йөрергә туры килә. Эшләгәч, тиешенчә бәяләнсәннәр иде.

Зилә. Зәй районы

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат үзәге:
– Мәгариф учреждениесе финанс нормативларына карап, укытучыларга һәм башка хезмәткәрләргә хезмәт хакын үзе билгели. Әгәр штат расписаниесе Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнмәгән булса, бу очракта мәгариф оешмасы компетенциясенә керә.

Эрнст СӘФӘРГАЛИЕВ, Зәй районы мәгариф идарәсе башлыгы:
– Мәктәп директоры урынбасары вазыйфасына кимендә биш ел һөнәри стажы булган педагогик хезмәткәрләр билгеләнә. Шулай ук муниципаль идарә, менеджмент өлкәсендә өстәмә һөнәри белем алу мәҗбүри шарт булып тора. Әлеге квалификация таләпләреннән чыгып, белем бирү учреждениесе җитәкчесе мәктәптә булган вакантлы вазыйфаларга билгеләп куярга мөмкин. Тәрбия һәм укыту эшләре буенча директор урынбасарларына эш хакы билгеләүне директор хәл итә.

ПЕНСИЯ: ЯҢА ЕЛДАН НИ КӨТӘРГӘ?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Россия халкының яртысыннан артыгы, пенсия алыр көннәрне күрә алырмынмы, дип борчыла. Шул ук вакытта илдә яшәүчеләрнең дүрттән бер өлеше пенсия мәсьәләләренә бөтенләй битараф икән. «Рамблер» порталы тарафыннан уздырылган соңгы сораштыру нәтиҗәләре шул хакта сөйли. Сораштыруда катнашкан кешеләрнең күбесе пенсиягә бәйле яңалыкларны даими күзәтеп баруын әйткән. Киләсе елда пенсия тармагында нинди үзгәрешләр көтелә? Россия Пенсия фондының Татарстан буенча бүлеге белгечләре «ВТ» укучылары юллаган сорауларга ачыклык кертте.

:: Киләсе елга кемнәрнең пенсиясе күпмегә артачак?

– Ел саен гыйнвар аенда эшләмәүче пенсионерлар пенсиясенең иминият өлеше индексацияләнә. Елдагыча, бу индексация дәүләт тәэмин итүе буенча пенсияләргә, шул исәптән социаль пенсияләргә, федераль ташлама иярәренә ай саен бирелә торган акчалата түләүләргә кагылачак. Аларның күпмегә артачагы әлегә билгесез. Индексация проценты ел башында Россия хөкүмәте карары белән билгеләнә. Август аенда һәрвакыттагыча алдагы елдагы иминият кертемнәре буенча эшләүче пенсионерларга каралган иминият пенсияләренә гариза язмыйча гына төзәтмәләр кертеләчәк.

:: Пенсиянең тупланма өлешен кайчан алырга була?

– 1967 елда туган яки аннан яшьрәк кешеләрнең, шулай ук пенсияне дәүләт финанславы программасында катнашучылар, ана капиталы акчасын булачак пенсиясенә күчергән кешеләрнең пенсия тупланмалары формалаша. Ир-атлар – 60 яшь, хатын-кызлар 55 яшь тулгач, тупланма өлешне алырга хокуклы. Әмма бу лаеклы ялга чыгар вакыты җиткән һәркем бу мөмкинлектән файдалана ала дигән сүз түгел. Әгәр кеше эшләгән чорда пенсиянең тупланма өлешен формалаштырмаган булса, ул аны берничек тә ала алмый. Лаеклы ялга чыккач та эшләвен дәвам иттергән пенсионерларга пенсия билгеләнгән көнгә счетта булган суммада акча түләнә. Пенсиянең тупланма өлешен алу өчен, Россия Пенсия фондына яки Дәүләтнеке булмаган пенсия фондына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бирәдә гариза язасы булачак.

:: Хезмәт пенсиясен алу өчен ничә ел эшләргә кирәк?

– Хезмәт пенсиясе алу өчен, ким дигәндә, 12 ел хезмәт стажы һәм пенсия коэффициентының 21дән дә ким булмавы кирәк. Агымдагы елда Россиядә картлык буенча иминият пенсиясе алуга хокук бирүче пенсия яшен арттыру буенча күчеш чоры дәвам итә. 1 гыйнвардан картлык буенча лаеклы ялга чыгу вакыты тагын бер елга артуга карамастан, быелгы пенсияләр яңа пенсия яшенә караганда 1,5 елга иртәрәк (хатын-кызларга – 56,5 яшьтә, ир-атларга 61,5 яшьтә) билгеләнә. Бу 2019–2020 елларда элеккеге пенсия яшенә җиткән кешеләр өчен махсус шартларның быел да гамәлдә булуына бәйле.

:: Эшләүче пенсионерлар нинди өстәлмәләргә өмет итә ала?

– Алдагы елда алар өчен иминият кертеме килеп ирешкән эшләүче пенсионерларның пенсиясе ел саен август аенда гариза язмыйча гына яңадан исәпләнә. Быел республикада барлыгы 256 мең эшләүче пенсионерның пенсиясе яңадан исәпләнде. Пенсия күләме, билгеле бер коэффициентка артучы традицион индексациядән аермалы буларак, августтагы яңадан исәпләү пенсионерның хезмәт хакы күләменә бәйле.

:: Туендыручыны югалту сәбәпле пенсия алам. Академик ял алырга җыенам. Ул очракта бу пенсия түләнерме икән?

– Академик ял алу, кияүгә чыгу, бала туу туендыручыны югалту сәбәпле пенсияне түләми башлау өчен нигез була алмый. Бу пенсияне тормыштагы шәхси сәбәпләргә бәйсез рәвештә 23 яшькә кадәр алырга була. Әмма бер шарт бар. Туендыручыны югалту сәбәпле пенсия алган кеше көндезге бүлектә укырга тиеш. Әгәр академик ял хәрби хезмәткә китү сәбәпле алынган булса, бу пенсия түләнми башлый.

:: Инвалидлык буенча пенсияне ничек рәсмиләштерергә?

– Инвалидлык буенча пенсияне рәсмиләштерү өчен Пенсия фондына бару мәҗбүри түгел. Аны Россия Пенсия фонды (www.pfr.gov.ru) яки «Дәүләт хезмәтләре» (www.gosuslugi.ru) порталында шәхси кабинет аша электрон гариза тапшырып та эшләргә мөмкин. Киләчәктә бу хезмәтне гаризасыз формага күчерү планлаштырыла, ягъни пенсия гражданинга инвалидлык билгеләнү белән автомат рәвештә билгеләнәчәк. Инвалидлык буенча пенсияләрнең барлык төрләре һәм аерым социаль түләүләр федераль инвалидлар реестрын кулланып рәсмиләштерелә. Россия Пенсия фондына мөрәҗәгать иткәндә, инвалидның гариза бирүе дә җитә. Калган мәгълүматларны фонд реестрдан һәм мәгълүмат системасыннан алачак. Узган елның язында коронавирус аркасында Россия Пенсия фонды тарафыннан кертелгән хезмәтләр алуның гадиләштерелгән тәртибе бүген дә гамәлдә. Киләсе елның мартына кадәр инвалидлык буенча пенсияләр медицина-социаль экспертиза бюросыннан инвалидлар реестрына килгән яңадан раслату турындагы мәгълүматлар нигезендә автомат рәвештә озайтыла.

:: Пенсияне кулга алып барам. Хәзер аны картага гына күчертәсем килә. Моның өчен ни эшләргә кирәк?

– Хәзер моны өйдән чыкмыйча гына да эшләп була. Аның өчен Россия Пенсия фонды яки «Дәүләт хезмәтләре» сайтындагы «шәхси кабинет» аша электрон рәвештә гариза тутырырга кирәк. Аны Пенсия фондына, яки күпфункцияле үзәккә барып тапшырсагыз да була. Пенсияне алу рәвешен үзгәрту турында гариза язганда «МИР» картасының 20 номерлы счетын да күрсәтергә кирәк.

:: 30 елдан артык авыл җирендә эшләгән кешеләрнең пенсияләренә өстәлмә булачак, диләр. Ул кемнәргә тиеш икән?

– Әйе, дөрестән дә, 2022 елның 1 гыйнварыннан 30 елдан артык авыл җирендә эшләгән пенсионерлар, кайда яшәүләренә карамастан, пенсияләренә өстәмә алачак. Хәзерге вакытта пенсионер башка җиргә күченеп киткән очракта, аның пенсиясенә өстәмәләр бетерелә. Киләсе елдан бу кагыйдә юкка чыгачак. Пенсионер башка җиргә күченеп киткән очракта да аның пенсиясенә өстәмә алу хокукы сакланачак.

Авыл җирендә эшләгән кешеләрнең пенсиясенә өстәлмә билгеләнгән түләүнең 25 процентын тәшкил итә һәм эшләмәүче пенсионерларга гына бирелә. Тагын шунысы да бар: авыл җирендә башкарылган теләсә кайсы эш авыл стажына кертелми. Анда Россия хөкүмәте тарафыннан расланган исемлектәге 500 төрле һөнәр, вазыйфа һәм белгечлек кенә исәпкә алына.

Авыл пенсиясенә өстәлмәләр авыл советында, авыл кибете, балалар бакчасы, медпунктта эшләгән кешеләргә түләнми. Бу мөмкинлек шәһәрдә эш стажы җыеп, соңрак авылга күченеп кайткан кешеләргә дә кагылмый. Гомер буе авыл җирендә эшләп, соңрак шәһәргә күченеп киткән кешенең пенсиясенә бу өстәлмә, ул кире авыл җиренә күченеп кайтып яши башлаган очракта гына кабат түләнәчәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

КИТКӘННӘР ДӘ КИРЕ КАЙТКАН

Пенсиядәге табибларның 25 проценты пандемия чорында кабат эш урыннарына әйләнеп кайткан. Бу хакта журналистлар белән очрашуда Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Илдар Фатыйхов хәбәр итте.

«Пандемияле ике елдагы статистиканы карап чыктык. Бу чорда пенсия яшендәге 700 табиб эштән киткән, шуларның 25 проценты кире әйләнеп кайткан», – ди ул. Гомумән алганда, узган ел республиканың дәвалау оешмаларында 1,7 мең кеше эштән киткән, 1858 кеше эшкә урнашкан. Министр урынбасары сүзләренә караганда, эштән китүчеләрнең бер өлеше лаеклы ялга чыккан, икенче берләре шәхси клиникаларга урнашкан. Араларында башка төбәккә күченеп китүчеләр дә бар.

Республика хастаханәләренә эшкә килүчеләрнең күпчелеген республика вузларын, аерым алганда, Казан дәүләт медицина университеты белән Казан (Идел буе) федераль университетын тәмамлаучылар тәшкил итә. «Башка ведомстволардан – 43 кеше, шәхси медицина оешмаларыннан – 160 табиб, башка төбәкләрдән 158 белгеч килде», – ди Илдар Фатыйхов. Соңгылары безнең республикада табибләр өчен кертелгән социаль ярдәм чараларына кызыгып килә дигән фикердә ул. Билгеле булганча, бүген Татарстанда «Земский доктор» һәм «Земский фельдшер» федераль программалары эшли. Алар ярдәмендә республиканың медицина оешмаларына 868 табиб һәм урта медицина хезмәткәре җәлеп ителгән. «Бу юнәлештә эшләүче тагын бер программа табибларга Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан социаль ипотека программасы буенча фатир алуга максатчан квота бирүдән гыйбарәт. 135 белгеч әлеге программа ярдәмендә фатирлы булды инде», – ди министр урынбасары.

Пандемия башланганнан бирле коронавирус белән авыручылар өчен оештырылган вакытлыча госпитальләрдә 17161 медицина хезмәткәре эшләгән. Шулай ук бу эшкә 883 «ашыгыч ярдәм» машинасы йөртүче һәм 1318 студент та җәлеп ителгән. Быел коронавируска каршы көрәштә медицина уку йортларында белем алган студентлар, ординатурада укучылар да катнашкан. Алар беренчел звенода хезмәт куйган. Казан дәүләт медицина университеты проректоры Алексей Шулаев сүзләренә караганда, студентларның күпчелеге бу тәҗрибәдән канәгать калган. Алар тыныч тормышта алып булмаган тәҗрибә туплауларына сөенә икән.

Илдар Фатыйхов сүзләренә караганда, хәзерге вакытта республика хастаханәләренә 1,2 мең табиб җитми. Татарстанның амбулатор хастаханәләре оториноларингологлар, психиатр, дерматовенерологларга кытлык кичерә. Кайбер районнарда участок терапевтлары белән педиатрлар да җитми. «Стационар хастаханәләрдә анестезиолог, реаниматолог, патологоанатом, неонатологларга кытлык зур. Кайбер районнарга табиб-фтизиатрлар җитми», – дип сөйләде министр урынбасары.



pixabay.com

20 декабрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 14.45, 17.00, 22.40 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
09.35 «Акыл баттл» 0+
10.00, 00.00 «ОРЛОВА И АЛЕКСАНДРОВ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл баттл» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Мин» 12+
17.30 «Татарстан без коррупции» 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Реальная экономика» 12+
22.30 «Вызов 112» 16+
00.50 «Соотечественники» 12+
01.15 «Черное озеро». Девушка против Бешеного 16+
01.45 «Память сердца» 12+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 6+
09.50 «Семь дней» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.00, 00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.45 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Оныта алмыйм» 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.35, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Даниил Страхов. «Знахарь». Новые серии (S) 16+
22.35 Праздничный концерт ко Дню работника органов безопасности Российской Федерации (S) 12+
00.25 К 125-летию Маршала Рокоссовского. «Любовь на линии огня» 12+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 Премьера. «КУЛАГИНЫ» 16+
17.15 «Андрей Малахов» 16+
21.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-21» 16+
23.35 «Вечер» 12+
02.20 «СОБАЧЬЯ РАБОТА» 16+
04.00 «БАЙКИ МИТЯЯ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.30, 15.45, 18.00 Новости
06.05, 19.10, 21.50, 00.15 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 12.35 Спец. репортаж 12+
09.20 «Любовь под грифом «Секретно». Док. фильм 12+
10.30 Зимние виды спорта. Обзор 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55, 01.05 «КРЮК» 16+
14.40, 15.50 «ПРОСПЕКТ ОБОРОНЫ» 16+
16.55 «Громко». Прямой эфир
18.05 Плавание. Чемпионат мира (бассейн 25 м). Прямая трансляция из ОАЭ
19.25 Хоккей. КХЛ. СКА (Санкт-Петербург) – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция
22.30 Смешанные единоборства. AMC Fight Nights. Алексей Махно против Руслана Колодко. Прямая трансляция из Белоруссии
00.45 «Есть тема!» 12+
02.15 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Автодор» (Саратов) 0+
04.05 Новости 0+
04.10 «Анатолий Тарасов. Век хоккея». Док. фильм 12+
05.05 «Громко» 12+

НТВ

04.55 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «БЫВШИХ НЕ БЫВАЕТ» (S) 16+
23.40 «НАЧАЛЬНИК РАЗВЕДКИ» (S) 12+
00.45 «Основано на реальных событиях» (S) 16+
03.30 «ГРЯЗНАЯ РАБОТА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «Реальная мистика» 16+
07.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.55 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Залюбить до смерти» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «ДВЕ ЖЕНЫ» 16+
19.00 «МОЙ МУЖЧИНА, МОЯ ЖЕНЩИНА». 1-я – 3-я серии 16+
22.15 «ПРОВОДНИЦА» 16+
02.20 «Реальная мистика» 16+
03.15 «Верну любимого» 16+
03.40 «Порча» 16+
04.05 «Знахарка» 16+
04.30 «Понять. Простить» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «СМЕРШ. ЛЕГЕНДА ДЛЯ ПРЕДАТЕЛЯ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20 «В ЗОНЕ ОСОБОГО ВНИМАНИЯ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25, 14.05 «СМЕРШ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Два дела Феликса Дзержинского» 16+
19.40 «Скрытые угрозы». «Альманах №84» 16+
20.25 «Загадки века». «Расстрел царской семьи. Судьбы палачей» 12+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.35 «КАМЕНСКАЯ». «СТЕЧЕНИЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВ» 16+
01.40 «Маршалы Сталина. Константин Рокоссовский». Док. фильм 16+
02.20 «Вторая мировая война. Город-герой Севастополь». Док. фильм. 12+
02.50 «Живые строки войны» 12+
03.15 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
03.30 «СМЕРШ» 16+

21 декабрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ…» 12+
10.00, 23.00 «ОРЛОВА И АЛЕКСАНДРОВ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «Ай тулганда» 12+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 « Не от мира сего…» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Трактор». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
00.00 «Видеоспорт» 12+
00.25 «Соотечественники» 12+
00.50 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
01.15 «Память сердца» 12+
01.30 «Не от мира сего…» 12+
01.45 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 07.40 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.30, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 6+
16.00, 00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30 «Тамчы-шоу» 6+
17.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Рәшит Зәкиев турында телеочерк 6+
18.20, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
19.00 Хоккей. КХЛ чемпионаты. «Ак барс» (Казан) – «Трактор» (Чиләбе). Трансляция Казаннан 6+
02.45 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә»(субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.15, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «ЗНАХАРЬ». Новые серии (S) 16+
22.35 Премьера сезона. «Док-ток» 16+
23.30 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.10 «Рецепт ее счастья» 12+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 Премьера. «КУЛАГИНЫ» 16+
17.15 «Андрей Малахов» 16+
21.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-21» 16+
23.35 «Вечер» 12+
02.20 «СОБАЧЬЯ РАБОТА» 16+
04.00 «БАЙКИ МИТЯЯ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.30, 15.45 Новости
06.05, 21.50 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 12.35 Специальный репортаж 12+
09.20, 14.40, 15.50 «ПРОСПЕКТ ОБОРОНЫ» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 «МатчБол»
13.30, 01.05 «КРЮК» 16+
16.55 Плавание. Чемпионат мира (бассейн 25 м). Прямая трансляция из ОАЭ
19.15 Хоккей. КХЛ. «Ак барс» (Казань) – «Трактор» (Челябинск). Прямая трансляция
21.15 Смешанные единоборства. PRO FC. Трансляция из Ростова-на-Дону 16+
22.40 Футбол. Кубок Английской лиги. 1/4 финала. «Арсенал» – «Сандерленд». Прямая трансляция
00.45 «Есть тема!» 12+
02.15 Волейбол. Евролига. Женщины. «Динамо-Ак барс» (Россия) – «Марица» (Болгария) 0+
04.05 Новости 0+
04.10 Баскетбол. Евролига. Женщины. «Динамо» (Курск, Россия) – «Баскет Ландес» (Франция) 0+

НТВ

04.55 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Сериал «БЫВШИХ НЕ БЫВАЕТ» (S) 16+
23.40 «Основано на реальных событиях» (S) 16+
01.20 Павел Прилучный, Станислав Дужников, Кристина Бродская. «РУБЕЖ» (S) 12+
03.00 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
03.30 Детективный сериал «ГРЯЗНАЯ РАБОТА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Реальная мистика». «Зубная магия» 16+
07.25 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.25 «Давай разведёмся!» 16+
09.30 «Тест на отцовство» 16+
11.45 «Понять. Простить» 16+
12.50 «Порча». «Чужое имя» 16+
13.20 «Знахарка» 16+
13.55 «Верну любимого» 16+
14.30 «ЛУЧШЕ ВСЕХ» 16+
19.00 «МОЙ МУЖЧИНА, МОЯ ЖЕНЩИНА». 4-я – 6-я серии 16+
22.15 «ПРОВОДНИЦА» 16+
02.15 «Реальная мистика» 16+
03.05 «Верну любимого» 16+
03.30 «Порча» 16+
03.55 «Знахарка» 16+
04.20 «Понять. Простить» 16+
05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «СМЕРШ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20, 18.30 «Спец. репортаж» 16+
09.35, 01.40 «ОТВЕТНЫЙ ХОД» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
13.40, 14.05 «ОХОТА НА ВЕРВОЛЬФА» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.50 «Два дела Феликса Дзержинского». «Заговор послов» 16+
19.40 «Легенды армии» 12+
20.25 «Улика из прошлого» 16+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.35 «КАМЕНСКАЯ». «ИГРА НА ЧУЖОМ ПОЛЕ» 16+
03.00 «Влюбленные в небо». Док. фильм 12+
03.25 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
03.40 «ОХОТА НА ВЕРВОЛЬФА» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 20–26 ДЕКАБРЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04) Мәзәк хәлләр, күңелле сюрпризлар булырга мөмкин. Әйтергә кирәк, аларның барысы да үзегезгә азмы-күпме файда китерер. Ләкин сабыйларча беркатлыланып, теләсә кемнең сүзенә генә ышанып йөри күрмәгез: алдануыгыз бар.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05) Кайсы гына яктан карасаң да, искиткеч уңайлы, әйбәт чор. Аеруча хатын-кызлар өчен. Аларның акылы, эчке һәм тышкы матурлыгы бик дөрес һәм гадел бәяләнәчәк. Аның каравы ир-атларга акча күбрәк керәчәк.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06) Ачу чыгарырлык хәлләр булып алыр. Әмма ничек тә тыныч, сабыр булып калырга, ачуны йөзегезгә чыгармаска кирәк. Юкса шушы халәтегездән дошманнарыгыз оста гына файдаланып калырга мөмкин. Иң зур сөенеч: әйбәт кенә акча кереме көтелә.

КЫСЛА (22.06 – 22.07) Бик шәп атна. Эшләргә яратасыз һәм эшли дә беләсез. Әҗерен күрергә вакыт – эштә искиткеч бәхетле чор көтелә! Акчасы дисеңме, абруй-хөрмәт, көтелмәгән бүләкләр дисеңме – барысы да нәкъ менә үзегез теләгәнчә булачак.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08) Бу атнаның нинди буласын аңлату өчен ике сүз җитә: сөенү һәм сөелү чоры. Атнаның беренче яртысында яңа танышларыгыз, бик тә акчалы өстәмә эшләрегез барлыкка килер, ә икенче яртысында үзегезгә карата моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә ихлас мактау, ярату-сөю сүзләре ишетелер.

КЫЗ (24.08 – 22.09) Көтмәгәндә генә үзегездә оештыру сәләте ачылыр. Бу тирәгезгә кешеләр туплау гына түгел, бәлки әле керемле эшләргә шәп кенә юл яру мөмкинлеге дә бирер. Гаиләгездә бераз гына үпкәләшеп алганнан соң татулашу өчен күңелле сәбәп килеп чыгар.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10) Талант дигәнне яшереп калып булмый, барыбер кайчандыр бәреп чыга ул. Менә хәзер сезнең өчен нәкъ шундый чор. Атна буе «ялтырап», тирәгездәгеләрне үзегегезнең искитмәле сәләтегез белән әсир итәчәксез.

ЧАЯН (24.10 – 22.11) Акыл сәләте, эчке сиземләү – барысы да тәртиптә. Яңа ел алдыннан баштанаяк эшкә чумсагыз да, бер нәрсәгә авырсынмыйча, барысын да җиңел башкарачаксыз.

УКЧЫ (23.11 – 21.12) Башыгызда искитмәле зур планнар туачак. Кайберләре инде бу атнада ук тормышка да аша башлаячак. Дусларыгыз арасыннан берсе көтелмәгән яңалык белән куандырачак.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01) Уңга-сулга карамыйча, һаман алга бару әйбәт анысы. Ләкин бу атнада ураурак юллар эзләү әйбәтрәк. Җитәкчегез кирәклесен бик тиз «эләктереп» алуыгызны ярата яратуын, ләкин күңеленнән генә хезмәттәшләрегезнең фикеренә дә колак салырга өйрәнүегезне тели.

СУКОЯР (21.01 – 19.02) Эш аты булу әйбәт, тик ял да кирәк. Эш дип, авыруга сабышып булмый, беразга гына аннан арынып торырга өйрәнегез. Гәрчә мондый мөнәсәбәт җитәкчегезгә бик үк ошап җитмәсә дә. Атна ахырында акча мәсьәләсендә күңелне күтәреп җибәрердәй яңалыклар ишетерсез.

БАЛЫК (20.02 – 20.03) Яңа ел алды атнасында матур гына яңалыклар көтегез. Барыннан да элек якыннарыгызга кагылышлы булыр кебек алар. Эштә гүя яңа сулышыгыз ачылыр – хезмәттәшләрегез сезнең уңышлардан хәтта көнләшә дә башлар.

КАТНАШ АЗЫК, АШЛЫК САТАМ.
Йомырка салучы тавыклар өчен катнаш азык

800 сум
Адрес: Казан, Техническая урамы, 15.
Телефон:
8 (927) 049-97-06

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail:
vtreklama@mail.ru

ЧӘЧСЕЗ КАЛМЫЙМ ДИСӘҢ, БАШЫҢА КИ!

Кыш – чәчләребез өчен аеруча авыр чор. Салкыннар башлану белән алар сына, зәгыйфьләнә, төссезләнә. Кыш көне чәчләрнең икеләтә күбрәк коелуы да күптән расланган. Бу күренеш нәрсә белән аңлатыла? Кышкы чорда чәчләрне ничек тәрбияләргә?

Табиб-дерматолог, косметолог, трихолог Эльвира САЛИХОВА белән шул сорауларга җавап эзлибез.

:: Эльвира Ринатовна, ни өчен чәчләр кышын күбрәк коела икән?
– Бу, нигездә, организмга витамин һәм микроэлементлар җитмәүгә бәйле. Шуңа күрә көзге, кышкы чорда витаминнар эчү аеруча файдалы.

:: Кайсы төр витаминнар турында сүз бара?
– Чәчләр сау-сәламәт булсын өчен, кыш көне В, Д, С төркеменә керүче витаминнар, кальций эчәргә кирәк.

:: Салкын көннәр чәчләргә ничек тәэсир итә?
– Кышын баш тиресендәге кан әйләнеше начарая. Нәтиҗәдә, чәчләргә файдалы матдәләр азрак килә башлый. Алар коры, төссез, сынучанга әйләнә. Шуңа күрә кыш көне баш киемсез йөрергә ярамый. Аеруча салкын көннәрдә чәчне тулысынча яшерү хәерле.

:: Баш киеменең нинди материалдан тегелгән булуы чәчләргә йогынты ясыймы соң?
– Һичшиксез йогынты ясый. Кышын синтетик материалдан тегелгән баш киемнәреннән баш тарту хәерле. Ник дигәндә, алар һава үткәрми.

:: Кыш көне чәч буярга ярыймы?
– Ярый, ләкин буяу сайлаганда игътибарлы булырга кирәк. Аларның составында аммиак булмаган, сыйфатлы төрләренә өстенлек бирү әйбәт.

pixabay.com

КЫШ КӨНЕ ЧӘЧЛӘР САУ-СӘЛАМӘТ БУЛСЫН ДИСӘҢ, ТҮБӘНДӘГЕ КАГЫЙДӘЛӘРНЕ ИСТӘ ТОТАРГА КИРӘК:

✷кышкы салкында чәчне югач ук урамга чыгарга ярамый. Салкында башка кимичә йөрү дә чәчләрне бик нык зарарлый;
✷кыш көне чәчләр зур стресс кичерә. Ник дигәндә, җилле, салкын урамнан керешкә, аларны ягып җылытылган бүлмәдәге коры һава каршы ала. Шуңа күрә кышын чәчләрне һәм баш тиресен даими рәвештә дымландырып торырга кирәк;
✷көн дәвамында чиста су эчү дә чәчләрне сәламәт килеш сакларга ярдәм итә;
✷чәч очларына махсус май сөртеп торсагыз да артык булмас.

:: Шампунь сайлаганда нәрсәләргә игътибар итәргә?
– Составындагы силикон, сульфатларга игътибар итәргә кирәк. Силикон – тулысынча синтетик матдә. Ләкин алар чәчләрне механик ысуллар һәм артык җылылык аркасында бозылудан саклый. Мондый шампунь белән юылган чәчләр шомара, ялтырый. Ләкин бу төркемгә кергән шампуньнарны чәч төпләренә, баш тиресенә тидерергә ярамый. Аларны чәчнең очыннан башлап, 3/2 өлешенә генә сөртергә кирәк. Сульфатлы шампуньнар исә чәчтәге аксымны юып төшерә. Нәтиҗәдә чәчнең очлары корый, баш тиресе кычыта, әрни.

Үлән генә димәгез

Күпләр, аз гына авырып китүгә, кул астындагы үлән чәйләре ярдәмендә дәвалана башлый. Саный китсәң, аларның нинди генә төрләре юк. Даруханәдә сатылганнары аеруча ышаныч уята. Күпкә китсә, дару да – агу, дигәндәй, чамасын белеп кулланмасаң, гади генә үлән чәе дә башка җитәргә мөмкин, ди белгечләр.

Татлы тамыр (солодка) чәе. Составында татлы тамыр булган чәйләр кеше гомере өчен куркыныч тудыра. Канаданың Макгилл университеты галимнәре шулай дип кисәтә. Белгечләр фикеренчә, татлы тамыр организмнан йөрәк эшчәнлеге өчен файдалы калийны юып төшерә, бөерләргә зыян сала. Мондый чәй яратучыларда гипертония дә пәйда булырга мөмкин.

Организмны чистартучы чәйләр. Сидек кудыручы мондый чәйләр бөерләргә авырлык китерүе, организмнан артык күп су чыгаруы белән куркыныч. Моннан тыш ул бөердәге ташларны да кузгата ала.

Сары мәтрүшкә чәе. Бу үлән, гадәттә, тынычландыргыч дарулар, хатын-кызлар өчен чыгарылган махсус препаратлар составында очрый. Сары мәтрүшкәнең салкын тигәндә, гастрит, колит, сару кайнаган чакта да файдасы зур. Әмма күпкә киткән очракта ул аллергия китереп чыгара, артериаль кан басымын күтәрә. Моннан тыш сары мәтрүшкә организмдагы файдалы химик элемент һәм кушылмаларны да юк итәргә мөмкин.

Канлы үлән чәен дә табиб киңәшеннән башка эчмәвең хәерле. Бу үләннең гайморит, артрит, ревматизм вакытында файдасы зур. Шул ук вакытта ул кан басымын төшерергә, ашказаны һәм эчәк юлларын яндырырга мөмкин.

Бөтнек чәе – ябыгырга теләүчеләрнең дошманы. Ник дигәндә, ул аппетитны ача. Балага уза алмаучы хатын-кызларга да бөтнек чәеннән баш тартырга киңәш ителә. Моннан тыш ул кан басымын да төшерергә мөмкин.

Срогы чыкса да ярыймы?

Кайбер төр даруларны срогы чыккач та кулланырга ярый. Икенче берләрен исә вакыты чыккан беренче көнне үк чүплеккә ыргыту хәерле, ди белгечләр.

Ярый	Ярамый
Каты дарулар (төймә һәм капсула рәвешендә). Әмма аларның кабы ачылмаган булырга тиеш. **Искәрмә!** Кайбер каты даруларны яраклылык вакыты чыккач кулланырга ярамый: **1) чыжылдый торган дарулар.** Алар бик тиз бозыла. Дымлы урында сакланса бигрәк тә. **2) нитроглицерин**. Андагы актив матдәләр бик тиз очып бетә. **3) антибиотиклар** белән дә бик сак булырга кирәк. Вакыты чыккан даруны эчкәннән соң икенче көнне нәтиҗәсе булмаса, аны кулланудан файда юк.	**Инъекция ясау өчен кирәкле ампула, флаконнар.** Алар төсен үзгәрткән, тоныкланган булса, аеруча куркыныч. **Сыек һәм йомшак дарулар** (гель, мазь, сироп, төнәтмә, тамчылар) **Киптерелгән үләннәр.** Вакыты чыккач, алар файдалы үзлекләрен югалта. **Инсулин** (саклаганда уала). **Тетрациклин.** Антибиотик агулы матдәгә әйләнергә мөмкин. **Пробиотик.** Алар составында саклаганда юкка чыга торган тере бактерияләр бар. **Контрацептив чаралар.**

Борчымаса да алмаштырасымы?

Берничә тешемдәге пломбалар 15–20 ел элек үк куелган килеш тора. Бер көнне танышым, аларны даими рәвештә алмаштырып торырга кирәк, дигәч, аптырап калдым. Тештәге пломбаны борчымаса да алмаштырырга кирәк микәнни?

СУФИЯ апагыз. Казан

Теш табибы Рөстәм НӘҖИПОВ:
– Тешләрне пломба ярдәмендә ямауның төп максаты тешне бербөтен итеп саклап калырга тырышудан гыйбарәт. Яхшы итеп куелган пломба тешне селәгәй, ризык калдыклары үтеп керүдән сакларга тиеш. Шул рәвешле ул аны бактерияләрдән дә саклый. Заманча пломбалар бик ышанычлы материаллардан эшләнгән. Шуңа күрә алар ун һәм аннан да күбрәк еллар дәвамында хезмәт итәргә мөмкин. Дөрес, моның өчен ямау эше сыйфатлы башкарылган булырга, тешләр даими рәвештә чистартылып торырга тиеш. Пломбаны алмаштырырга кирәкме-юкмы икәнлеген үзлегеңнән генә ачыклау кыен. Кеше тешкә тел белән кагылганда авырту сизелгән очракта гына хәлнең мөшкел икәнлеген чамалый ала. Бу очракта табибка баруны кичектерергә ярамый. Ул, тешләрегезне тикшереп, кирәк дип тапса, иске пломбаны яңасына алмаштырачак.

Үзем сынадым

Гастриттан бал булышты

Кызым гастриттан интегә. Соңгы арада балның файдасын күрә башладык. Сезнең белән дә бүлешим әле. Бик җайлы рецепт. Бер стакан җылымса суга 1,5 чәй кашыгы бал салып болгатасың да, ашар алдыннан ярты сәгать кала эчеп куясың. Файдасы шундук сизелә.

ФИРАЯ апагыз. Әлки

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ҮЗЕҢ ӘЗЕРЛӘҮ ЯХШЫРАК

Яңа елны Кыш бабайның тәмле-татлы күчтәнәчләреннән башка күз алдына да китереп булмый. Ә кибетләрдә ниндиләре генә юк! Тик киштәләрдә ялтыр-йолтыр килеп торучы каплардагы шоколад-кәнфитләрнең сыйфаты гына кайвакыт шиккә салырга мөмкин. Күчтәнәч нәниләрне сөендерәсе урынга бәйрәм кәефенә китереп «сукмасын» өчен, нәрсәләрне белеп торырга? Аллы-гөлле Яңа ел җыелмаларыннан баш тартып, татлы бүләкне үзебез сатып алган «тәмлүшкә»ләрдән генә әзерләсәк, ничек була?

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Татарстанда Гигиена һәм эпидемиология үзәге» оешмасының азык-төлек гигиенасы, балалар һәм үсмерләр гигиенасы бүлеге мөдире Ренат МУСИН татлы бүләк сайлау буенча киңәшләрен бирде.

Арзанлы бүләккә кызыкмагыз. Сатып алганчы, иң элек кәнфит-шоколадлар җыелмасын ясаучы фирма турында мәгълүматларның, телефон номерларының күрсәтелгәнме-юкмы икәнен барлагыз. Әйбәт җитештерүчеләр каптагы барлык күчтәнәчнең тулы исемлеген генә түгел, бәлки әле тәм-томнарның гомуми составын, кайчан җитештерелүен, яраклылык вакытын да күрсәтә. Сүз уңаеннан, ел символы булып торучы җәнлек – йомшак уенчык эченә тутырылган татлы бүләкләрне үзегез белгән яки танышларыгыз киңәш иткән фирмалар аша гына сатып алыгыз. Ник дигәндә, Яңа ел алдыннан акча эшләп калырга маташучы бер көнлек фирмалар бик күп пәйда була. Алар Кытайда җитештерелгән сыйфатсыз уенчыкларны шалкан бәясенә күпләп сатып ала да шуларга арзанлы кондитер әйберләре тутыра.

Саклау вакытына килсәк, түбәндәгеләрне истә тотарга кирәк. Яңа ел җыелмалары гадәттә инде сентябрь – октябрь айларында ук хәстәрләнә. Димәк, дөрес саклаганда, алар искерә-бозыла башларга мөмкин. Шуңа күрә составында тиз бозылучан продуктлар (әйтик, кремлы кондитер ризыклары, йогыртлар) булганын читләтеп узу хәерлерәк.

Яңа елга балаларга сюрпризлы шоколад йомыркалар, шоколад сыннар да күп бүләк ителә. Мондый тәм-томнар арасында да сыйфатсызлары очрый. Сюрпризлы «тәмлүшкә» составында какао мае микъдары 35–40 проценттан ким булмаска тиеш. Юкса җитештерүчеләр экономияләү максатында бу таләпне еш кына боза. Ә инде йомырка тышында күрсәтелгән саннарга ышанмасагыз, өйгә кайткач, сыйфатын үзегез тикшереп карагыз. Моның өчен аны, балалар күрмәгәндә, әлбәттә, яндырып карарга кирәк. Сыйфатсыз икән, борынга шундук әшәке пластмасса исе килеп бәреләчәк. Кызыл ялкын чыгарып янса, димәк, сыйфатлы. Ә инде шоколад зәңгәр ялкынга чорналса, йомырка тоташ химиядән тора, дигән сүз. Аны әнә шулай сынап карап кына алу хәерле.

Әкият геройларына охшатып ясалган шоколад сынга да тукталып үтәргә кирәк. Аның составына игътибар итмичә калмагыз. Намуссыз җитештерүчеләр какао маен пальма маена алыштырырга да күп сорап тормый. Ә мондый шоколад балаларга гына түгел, олыларга да зыянлы.

Дөресен генә әйткәндә, Яңа елның татлы күчтәнәчен үзебез әзерләүдән дә яхшысы юк. Бу очракта ул бала ярата торган искермәгән, әйбәт кәнфитләрдән генә торачак. Шул ук вакытта бүләкнең бер өлешен файдалы тәм-томнарга, ачы шоколад, киптән җимешләр, мюсли батончиклары һәм чикләвекләргә алыштырып булачак.

Аш-су

Яңа ел табынына каз пешерү ысуллары

ӘНҖЕ ХӘМИТОВА РЕЦЕПТЫ

Казны бер тәүлеккә тозлы суга салып тотабыз. Шуннан полиэтилен җиңсәгә урнаштырып, газ миченә куябыз. Зурлыгына карап, 1,5–2 сәгать чамасы пешә. Тәмләткечләр, майонез сыларга кирәкми. Пешеп чыккач, бераз суынганнан соң 3–4 тырнак сарымсак (күбрәк тә ярый) уып, эченә-тышына сылыйбыз да азык-төлек пленкасына төреп куябыз. 2 сәгатьтән телеңне йотарлык каз әзер!

ГҮЗӘЛИЯ ШӘРӘФИЕВА РЕЦЕПТЫ

10 литр суга ярты каптан аз гына күбрәк тоз салып, кайнатып чыгарабыз. Кәстрүлнең зурлыгына карап, казны бүлеп яки бүлмичә салабыз. Кайнап чыккач, 1,5 сәгать чамасы уртача утта пешерәбез. Уттан алгач, итне шулпасында 2 сәгать тотабыз. Суынгач, турыйбыз. Бик тәмле, сусыл ит килеп чыга. Сөягенә кадәр тоз тәме үтә.

ЛӘЙСӘН НУРГАЛИЕВА РЕЦЕПТЫ

Казны кичтән тозлы суга салып куябыз. Иртән, кәгазь сөлге белән корыткач, эченә-тышына мул итеп аджика, 3–4 тырнак сарымсак (угыч аша уып), бер лимон согы сылыйбыз. Каз эченә 1 әфлисун (кабыгыннан чистартып), ярты лимон (телемләп кисеп), 1 алма, 2–3 кара җимеш тутырып, фольгага төрәбез. Газ миченә ике сәгатькә пешерәбез. Пешкәч, фольганы ачып, казның өстен кызартып алабыз.

Остахана

Нәни чыршы

Өйдә «урман сылуы»на урын юк икән, хуш исле мини-чыршы ясап куярга мөмкин. Моның өчен махсус флористик губка (чәчәк кибетләрендә арзан гына бәядән сатыла) яки пенопласт кирәк. Шул «күбек»кә чыршы яки нарат ботаклары тыгабыз. Үзебез теләгәнчә бизәп, өстәл уртасына куябыз. Хуш исле ботакларны чәчәк вазасына урнаштырырга да була.

Кирәге чыгар

Мандаринга тәм кертәбез

Яңа ел алды ыгы-зыгысы башлана. Гадәттәгечә, бу чорда кибет киштәләре мандариннар белән тула. Әмма кайвакыт цитрус җимешенең эчеләре дә әләккәли. Ник дигәндә, агачтан алар өлгереп җитмәгән килеш җыела. Юлда бозылып, әрәм-шәрәм булмасыннар өчен шулай эшләнә.

Әче мандаринга тәм кертү ысуллары бар. Беренчесе бик җиңел һәм тиз, икенчесе күбрәк вакыт таләп итә.

Озак ысул. Өлгереп җитмәгән мандариннарны җылылык батареясы янына тигез өслеккә тезеп куябыз. Җимешләр берсе-берсенә тиеп тормаска тиеш. Җылылык тәэсирендә алар 3–5 көннән соң өлгереп, татлы булачак.

Җәһәт ысул. Әгәр инде мандаринның өлгерүен көтеп торырга вакыт та, теләк тә булмаса, аңа ярты минут эчендә тәмле тәм кертергә мөмкин. Кыска дулкынлы мичне кабызып, җимешне шунда 30 секундка гына куеп торырга кирәк.

КАР БӨРТЕКЛӘРЕ, БӘСЛЕ БОКАЛЛАР...

Чыршы ботакларын ясалма кар бөртекләре, бәс белән капларга мөмкин. Ничек итеп, дисезме?

Моның өчен тоз булса, шул җитә. Тоз һәм кар бөртекләренең төзелеше бер-берсенә бик охшаш чөнки. Кар ясау өчен 1 стакан суга 2 аш кашыгы тоз салып, эремә әзерлибез. Тоз суда эреп беткәч, бәс белән каплыйсы әйберне, әйтик, чыршы ботагын эремәгә тыгабыз. Бераз торткач, алабыз да киптерергә куябыз. Ботакка бик матур «бәс» кунып, өстендә «кар бөртекләре» калачак.

Тоз урынына шикәр комы кулланырга да мөмкин. Монысы бокал-стаканнарның читләрен бәс белән каплау өчен бик әйбәт. Бокал читен шикәрле суга тыгып алабыз да гадәти шикәр комына тидерәбез. Кипкәч, эчемлек салабыз.

Ә инде чыршы төбенә сибү яки аппликацияләр ясау, бүләкләрне бизәү өчен ясалма карны яңа аяк киеме тартмасындагы пенополиэтиленнан (җитештерүчеләр аны аяк киеменең формасы бозылмасын өчен сала) ясыйбыз. Моның өчен аны угыч аша чыгарырга гына кирәк.

МАТУРЛЫКНЫ НИЧЕК САКЛАРГА ҺӘМ КАЯ КУЯРГА?

Чын чыршы өйдә озак саклансын өчен, аны чиләктәге марганцовкалы суга утыртып куярга кирәк. Эремәнең куе булуы әйбәт. Болай эшләгәндә, урман гүзәле, кырыеннан яшь ботаклар чыгарып, 23 февральгә кадәр бөтен матурлыгын саклаячак. Ә инде аны кая урнаштыруга килгәндә, кызык кына сынамышлары бар.

✓ Киләсе елда яңа дуслар табарга, киракле кешеләр белән элемтәләр корырга теләсәк, бүлмәнең сул як почмагына куябыз.

✓ Карьера баскычыннан өскәрәк үрмәләргә теләсәк – бүлмә ишеге алдына ук.

✓ Гаиләдәге мөнәсәбәтләрне яхшыртырга ниятләсәк – бүлмә ишеге төбенә уң якка.

✓ Күбрәк акча керүен теләсәк – ишек төбенә сул якка.

Сәхифәне Валентина СЕМЕНОВА әзерләде

АШАГАН КҮРЕНМИ, КИГӘН КҮРЕНӘ

Аллаһы Тәгалә Коръәндә: «Бөтен зиннәтләрегезне ябыгыз, фәкать шул рөхсәт ителгәннәрдән кала», – дип кисәтә. Әлбәттә, сүз – тәнебезгә кигән киемебез хакында. Шөкер, җитеш заманда яшибез, җан теләгән, кесә калынлыгы рөхсәт иткән теләсә нинди кием-салымны алырга мөмкинлек бар. Шулай да, мөселман кешесенең киенү рәвеше нинди булырга тиеш? Җәнлек сурәте, ниндидер сүзләр төшерелгән кием киярге рөхсәтме? Хатын-кызлар, ир-атлар өчен аерым чикләүләр бармы?

dumrt.ru

Бу һәм башка сорауларга җавапны «Ихлас» мәчете имамы Али хәзрәт ХӘСӘНОВ бирде.

:: Динебездә мөселман кешесенең киенү рәвешенә бәйле нәрсә әйтелә, хәзрәт? Хатын-кызларга, ир-атларга билгеле бер чикләүләр бармы?

– Исламда билгеле бер кием төре юк, әмма кеше киячәк киемгә карата таләпләр бар, чөнки мөселманнар Мәккәдәге мөселман булмаганнар кигән киемне үк кигән. Иң элек кием гаурәтне капларга тиеш. Хатын-кызда бу – кул чугы һәм битеннән кала бөтен гәүдәсе, ир-атның исә киндектән алып тезенә кадәр өлеше. Кием сыланып торырга, үтә күренмәле булырга тиеш түгел. Кием-салым кешенең башка дингә тугрылыгын күрсәтмәскә, күзгә бәрелеп тормаска һәм игътибарны җәлеп итмәскә тиеш.

:: Мөселманның төсе – яшел, дигәнне ишеткән бар. Ислам динендә төс берәр нинди әһәмияткә ияме?

– Исламда ир-атның кызыл төстәге кием киюен тыйган кайбер хәдисләрдән тыш, төскә кагылышлы катгый таләпләр юк. Пәйгамбәребез (с.г.в.) сүзләренә карaганда, иң яхшы кием – ак төстәгесе. Габдулла ибн Габбас аның сүзләрен болай дип китерә: «Ак төстәге киемнәр киегез. Чынлыкта алар иң яхшы киемнәрдән санала. Һәм җәсәдләрне дә акка төрегез».

:: Карадан киенеп, төренеп йөргән хатын-кызлар очрый. Бу – мөселманнарга хас киемме?

– Әгәр санап үтелгән барлык шартлар үтәлгән икән, хатын-кыз теләсә нинди төстәге киемне кия ала.

:: Гомумән, хатын-кызларга карата «син өеңдә генә, үз ireң өчен генә матур киенергә тиеш» дигән фикерләр бар. Бу шулаймы?

– Аллаһы Тәгалә хатын-кызны матур итеп яраткан һәм аның матурлыгын бары тик лаеклылар гына күрә ала. Бу матурлыкка соклану хокукы да иң якыннарга гына бирелгән. Галим табигыйннарның китапларыннан шуны аңлыйбыз: хатыннар – ирләре өчен, ә ирләре хатыннары өчен киенгән. Исламда гаилә мөнәсәбәтләренең зиреклеге һәм матурлыгы әнә шунда тупланган да инде. Ире өчен ул нинди булып күренә – хатын-кыз өчен дә бит иң мөһиме шул булырга тиеш. Өйдә иске халаттан, бигудидан, төс-кыяфәтенә игътибар бирми, ә җәмгыятькә чыкканда, башка ир-атлар өчен киенеп-ясана торган хатын-кызлар да бар, мондый мисаллар хәзерге тормышыбызда да җитәрлек. Моны ир-атларыбызга карата да әйтеп була.

:: Хәзер никах өчен нинди генә матур күлмәкләр юк. Тик күбесе нык сыланып тора, муенны да капламый. Мәчеттә уза торган никах чараларына да күпләр шундый киемнән килә. Болай киенү дөресме соң?

– Тәненең аз гына өлешен ачып йөрткән кеше гөнаһлы санала. Кызганыч, сыланып торган, муены ачык, билне кысып торган кием кию рөхсәт ителә дигән ялгыш фикерләр бар хәзер. Бу – дөрес түгел. Әйтүемчә, моны кылган кеше гөнаһлы санала.

:: Җәнлекләр, ниндидер сүзләр төшерелгән кием кию рөхсәт ителәме?

– Динебездә җанлы предметларга, хайваннарга, кеше сурәтләренә карата кырыс караш бар. Сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.), йорт эчендә җанлы әйбер сурәтләре, статуэткалар булса, рәхмәт фәрештәләре кермәс, дип әйткән. Шуңа күрә мондый сурәтләр төшерелгән киемнәрне кимәү хәерле. Сүзләргә килгәндә, аларның мәгънәсенә игътибар итәргә кирәк. Алар хәрам, оят гамәлләргә, мәҗүсилеккә өндәмәскә тиеш.

:: Иске киемнәрне кемгәдер бирергә ярыймы? Кемдер бит, хорафатларга ышанып, аны йә яндыру, йә җыеп, саклап тоту яклы.

– Әгәр рәсүлебез һәм аның көрәштәшләренең гамәлләренә карасаң, алар кием-салымны мохтаҗларга ярдәм итү максатыннан да, яхшы хәбәр өчен бүләк буларак та биргән. Хәдисләрдә әйтелгәнчә, пәйгамбәребез (с.г.в.) яңа кием кигәнне бер иптәше карап торган да үзенә сораган. Рәсүлебез ике дә уйламый, киемне аңа биргән.

Исламда исраф кылу тыелган. Кешегә нинди дә булса кием кирәкми, әмма ул әле сыйфатлы, киярлек икән, аны мохтаҗларга бирү мөмкин. Ул сәдака буларак та саналачак. Кеше биргән киеме өчен Аллаһы Тәгалә рәхмәтен алачак. Шушы мисаллардан чыгып әйткәндә, кемгәдер файда китерерлек киемне утка ягу дөрес үк булмас. Диндә исә бу гамәлнең ихтыяҗын расл аган дәлил дә юк.

Кеше яңа кием сатып алганда, Аллаһы Тәгаләдән бәрәкәт сорарга тиеш. Моннан тыш, тирә-юньдәгеләр дә дога кылып, аның белән бергә шатланса, бик хәерле булыр.

ЯРАТУ УЛ – ҮЗЕҢ ТУРЫНДА ОНЫТУ

Гыйбрәт ал!

Локман Хәкимнең бер дусты булган, Локман Хәкимне шулкадәр хөрмәт иткән: ризыгын да иң элек аңа тәкъдим итә торган булган. Бервакыт аңа кавын бүләк иткәннәр. Ул, кавынны кисеп, Локман Хәкимгә биргән, Локман Хәким бик тәмләп ашый башлаган. Аңа кызыгып, дустының да ашый башлавы булган, кавын авызга алгысыз ачы булган. Гаҗәпләнеп: «Ни өчен ачы дип зарланмадың?» – дигән. «Мин кавынга түгел, бирүче кулга игътибар иттем. Чын дус кулында ачы әйбер дә татлы була, чын дус янында караңгылык та кимеп китә, авырлыклар да җиңеләя», – дигән. Ярату ул – үзең турында онытту. Чын дус дустының мәнфәгатен үз мәнфәгатьләреннән өстен куя, ул синең өчен тырыша (яхшы табиб кебек). Табиб та бит укол кадарга да мөмкин, әче дару бирергә дә, операция ясап, кайсыдыр җиреңне кисеп авырттырырга да мөмкин, ләкин ул аны синең өчен эшли. Кайвакыт дусларның туры сүзен кабул итә алмыйбыз, үпкәлибез, араларны өзәбез. Хаталарыңны күреп төзәтергә тырышучыларны читкә тибәреп, яныңнан куып харап була күрмә.

(«Локман Хәким нәсыйхәтләре» китабыннан)

pixabay.com

Өч хәдис

- Үзенә теләгәнне кардәшенә теләми торып, берегез дә иманлы булмас.
- Кешегә башкалар алдында хур булу өчен дүрт нәрсә җитә: бозык булу, каты телле, саран һәм куркак булу.
- Ахирәттән кала бөтен эшләрдә дә ахырын уйлау һәм сабыр итү кирәк.

Бу кызык!

Пәйгамбәребез турында нәрсә беләбез?

Сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.) ана карынында чагында ук әтисез калган.

Аңа 6 яшь булганда әнисе үлә, рәсүлебез бабасы тәрбиясендә кала. Ул да ике елдан соң бакый дөньяга күчә.

Пәйгамбәребез 25 яшендә Хәдичә исемле, тол, зирәк, үзеннән 15 яшькә олырак хатын-кызга өйләнә.

Хәдичә анабыз белән сөекле пәйгамбәребезнең 6 баласы була. Болар – Касыйм, Габдулла, Фатыйма, Зәйнәп, Өмме Көлсем, Рокыя.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

АЛМАЗ МИРЗАЯНОВ:

«МИН ҮЗЕМЧӘ ЯШӘРГӘ БУЛДЫМ»

Җырчыларның «урак өсте» башланды. Яңа ел кичәләрендә катнашу, концертлар, съемкалар, йомгаклар... Берсен дә тотып булмый. Шулай да «Ни хәл?» сәхифәсенә алып баручы, җырчы Алмаз МИРЗАЯНОВны чакырып, гастрольләр, эстрада һәм гаилә хәлләре турында сөйләштек. «Челтәрле бизнес» та читтә калмады.

:: Ни хәл?
– Бар да яхшы. Яңа ел җитә бит, соңгы арада төрле тапшыруларда төшәбез. Әле менә «Яңа Гасыр» телеканалы чакыруы буенча, бәйрәм төнендә күрсәтеләчәк мюзиклда катнаштык.

:: Күптән түгел «Болгар радиосы»ның милли музыкаль премиясе бәйгесендә «Елның гаилә дуэты» исеменә лаек булдыгыз. Бүген эстрадада парлы җырчылар җитәрлек, ә сезнең үзенчәлек нидә дип уйлыйсыз?
– Җитәрлек, дисәгез дә, бүген гастрольләр белән концерт куеп йөрүче пар икәү генә. Берсе – без! Аллаһка шөкер. Бәлки шуңа күрәдер дә, «Болгар радиосы» иҗатыбызны шулкадәр зур дәрәҗәдә бәяләде. Зур рәхмәт аларга!

:: Концертлар, дигәннән, ничек соң, тамашачы йөриме, заллар туламы?
– Аллаһка мең шөкер, концертларыбыз тукталып калмады. Мондый катлаулы вакытта безне яраткан, бик тә хөрмәт иткән тамашачылар гына киләдер ул. Без дә, үз чиратыбызда, аларны өряңа программа белән сөендерергә әзерләндек. Быел аеруча сәхнә бизәлешенә, киемнәргә зур игътибар бирергә тырыштык. Программага күп яңалыклар керттек. Шуңадырмы, быелгы концертларны аеруча яратып кабул итәләр. Һәр концерт ахырында басып алкышлыйлар. Бу инде – безнең өчен иң зур бәя.

:: Башка яшь парларга язган кебек, сездән дә бәби сорап язучылар бармы? Моңа ничек карыйсыз?
– Мондый шәхси сорау бирергә бары тик иң якын кешеләрнең генә хакы бар дип саныйм.

:: Күптән түгел Шәкүр (Алмаз-Әмирхан Корбанов) белән сезнең өчен бөтенләй яңа юнәлештәге җырыгыз чыкты. Мондый тәҗрибә ошадымы?
– Аның язылу һәм яздырту тарихы болайрак булды. Адаш бергә җырлап карарга тәкъдим ясады, ә мин каршы килмәдем. Нәтиҗәсе ошады, дип, егылып китеп әйтә алмыйм. Мин – үзем теләгәнчә эшләргә ярата торган кеше. Ә монда башкачарак килеп чыкты. Минем проект булмагач, Шәкүр үзе теләгәнчә эшләде. Шуңа да карамастан, нәтиҗәсе яхшы, диләр. Гәрчә яхшы тәҗрибә булса да, мин башкарган өлеше үземә ошамады.

:: Эстрада дигәч, «челтәрле бизнес» күз алдына килә торган көнгә килеп җиттек. Соңгы арада аңа карата бик күп тискәре фикерләр яңгырый...
– Тискәре фикерләргә карата бер генә дә дәлилле фактлар юк бит. Мин ике ел дәвамында бу продуктларны кулланып, файдасын күреп килдем. Компаниядә эшли башлавым да шуннан соң гына булды. Бүген дә күрәм. Беркемне дә алдаламыйм, намусым чиста. Иҗатта эшләгән акча иҗат итү өчен җитми бүген. Ә концертлар куясы килә.

Кеше сөйли инде ул. Белсә дә, белмәсә дә. Бер бәйләнерлек әйбер эшләмәгәндә дә әллә ниләр яздылар. Шуңа күрә мин үземчә яшәргә булдым. Һәр кеше фикере янында тукталып торсаң, теләгәнне эшләп, теләгәнне ашап, теләгән җиргә барып, үзең теләгәнчә яшәп булмый ул. Җинаять кылмыйм, беркемне дә мәҗбүр итмим.

Блиц-сораштыру

– Яратып укыган китапларыгыз?
– Аның әтисе Аллаһияр Шәех 1512–1516 елларда Касыйм ханлыгында солтан булып тора. Шаһгали 1506 еллар тирәсендә туа һәм руслар даирәсендә тәрбияләнә. 1516 елда әтисе үлгәннән соң, 10 яшьлек улын Касыйм тәхетенә күтәрәләр. Казан ханы Мөхәммәд Әмин вафат булганнан соң, Мәскәү кенәзе Василий III аны 1518 елның декабрендә Казанга җибәрә. Әлбәттә, балигълык яшенә дә җитмәгән Шаһгали руслар өчен бик кулай кандидатура була. 1519 елның 1 мартында Мәскәүдә Казан делегациясе катнашында яңа ханны тәхеткә утырту тантанасын бәйрәм итәләр. Шаһгали дә, делегация дә, бер атнага сузылган күңел ачулардан соң, Мәскәү мәнфәгатьләрен сакларга ант биреп, Казанга кайтып китәләр. Анда яңа ханны шатланып каршы алмыйлар. Рус елъязмачысы сүзләренә караганда, Шаһгали, яшь кенә булуына карамастан, ярыйсы ук тулы гәүдәле, кыска муенга утыртылган зур башлы, иңсәләренә кадәр асылынып торган озын колаклы, маймылныкына тартым куллы һәм хатын-кызларныкына охшаш, әмма ямьсез йөзле, күңел чиркандыргыч бер кеше була. «Татарларны мыскыллау өчен патша аны махсус сайлагандыр, күрәсең», – дип яза, кинаяле көлеп, рус елъязмачысы. Аңлашыла ки, халык арасында Шаһгалинең бернинди дә абруе булмый. Хәер, аңа хан роленә керергә дә мөмкинлек бирмиләр: Шаһгали исеменнән Мәскәү илчесе идарә итә. Элегрәк югары урыннарны биләп торган Казан түрәләре ризасызлык белдерәләр. Русларга каршы оппозиция оеша. Аның вәкилләре Кырым ханы белән элемтәгә керәләр. Шаһгали үзенә каршы торучыларга: «Күреп торасыз ич, Мәскәү Казанга караганда көчлерәк, без аны берничек тә үзебезгә буйсындыра алмаячакбыз. Кырым ханына да ышаныч юк, ул да безне үзенә буйсындырырга тели», – дип җавап бирә. Шулай да казанлылар Бакчасарайга яшерен делегация юллыйлар һәм Казан тәхетенә Кырым ханы Миңлегәрәйнең улы Сәхибгәрәйне җибәрүләрен сорыйлар. Сәхибгәрәй 1521 елның язында 300 кешелек гаскәре белән Казанга юнәлә, ә Кырым һәм Нугай гаскәрләре Мәскәү чикләренә үтеп керәләр. Сәхибгәрәй отряды Казанга керү белән шәһәрдә мәхшәр башлана – казанлылар Шаһгалигә каршы күтәрелә. Ул 300 кешелек гаскәре һәм рус илчеләре белән Казаннан чыгып кача.

:: Касыйм шәһәре бүгенге Рязань өлкәсендә, Мәскәүдән 300 чакрым ераклыкта гына. Татарлар анда ничек килеп чыккан? Шаһгали туып үскән Касыйм ханлыгының тарихы кая барып тоташа?

– Касыйм ханлыгы – Кырым, Казан, Әстерхан, Себер ханлыклары кебек үк Алтын Урданың бер варисы. Күп кенә тарихчылар тарафыннан Казан ханлыгына нигез салучы дип исәпләнә торган Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәд, 1437 елда Кече Мөхәммәд тарафыннан тәхетеннән куылганнан соң, рус җиренә, Белев шәһәре тирәсенә кача. Аның бер улы хәзерге Рязань җирлегендә, тарихка үзенең исеме белән кереп калган Касыйм ханлыгына нигез сала. Касыйм ханнары, Мәскәү кенәзләре белән төзелгән килешү шартларында каралганча, атлы гаскәрләре белән Рус дәүләтенең көньяк чикләрен сакларга тиеш булалар. Әмма бу алар тулысынча Мәскәүгә бәйле булган дигән сүз түгел.

:: Касыйм ханлыгы белән Казан ханлыгы арасындагы үзара мөнәсәбәтләр нинди булган?

– Бу ике ханлык үзара сугыш алып бармаган. Әмма тарихта Касыйм татарларының Мәскәү гаскәрләре составында Казанга яу чабулары билгеле. Ахыр чиктә алар Казан ханлыгын басып алуда да катнашалар. Шулай ук башка татар дәүләтләрендә дә (мәсәлән, Ногай Урдасында) талау оештырганлыклары турында язылган истәлекләр бар. Ә минем Казан татарларының Касыйм татарларына яу белән барулары турында бернинди мәгълүмат та очратканым юк. Мәскәү белән мөнәсәбәтләргә килгәндә, алар Касыйм ханлыгын Мәскәү дәүләтенең бер өлеше итеп санаганнар, ә Казан ханлыгы исә Алтын Урданың бер кыйпылчыгы – дошман булып кабул ителгән.

:: Шаһгали җиде тапкыр хан дәрәҗәсенә күтәрелгән. Нинди генә булса да, аңа мөрәҗәгать иткәннәр бит. Димәк, моның төбендә нидер ята. Ханның патшаларга якынлыгы, үзенчәлеге нәрсә белән аңлатыла?

– Чыннан да, бик каршылыклы шәхес ул Шаһгали хан. Татар тарихында аннан да тискәрерәк персонажны хәтерләмим. Шул ук вакытта аны белмәгән кеше дә юк. Кайбер тарихчылар, журналистлар Шаһгалинең сыйфатларын тасвирлау өчен нинди генә ямьсез сүзләр кулланмыйлар. Минемчә, Шаһгалинең фаҗигасе шунда: ул читләр арасында – үз кеше, үзенекеләр арасында чит кеше булган. Тарих битләреннән күренгәнчә, моны аңлаучылар да байтак. Ә үзенчәлегенә килгәндә, күзгә күренеп торган, гаҗәпләнерлек берни дә юк. Ул Мәскәү өчен бик уңайлы «курчак» ролен уйный. Аны тәхеткә утыртканнар да, мәскәүлеләр үзләре ничек теләгәннәр, шулай идарә иткәннәр. Ни өчен шулай килеп чыкканмы? Шаһгали, беренчедән, Рязаньда туып үскән, руслар арасында тәрбияләнә. Мәскәү аны туендыра, ашата, эчертә. Мәскәү сәясәте аның өчен иң дөресе була. Мәскәү – аның туган җире, ул башканы белми. «Үзенчәлек» дигән нәрсә менә шуңа корыла да инде.

:: Идарәче буларак ул нинди кеше булган? Үз халкына файдалы эшләр эшли алганмы?

– Телгә алып сөйләрлек эшләре дә юк кебек. Әмма кайбер «кайнар башлар» әйтүенчә, ул бөтенләй үк руслар яклы да булмый. Мәсәлән, Иван IV Казанны яулап алыр алдыннан Мәскәү гаскәрләрен Казанга кертүдән баш тарта. Гомумән, ул теләсә кайсы сәясәтче кебек үк, вазгыятькә карап, үзен төрлечә тотарга мәҗбүр була. Бервакыт шулай Мәскәүгә каршы булган Казан түрәләрен җыеп мәҗлес ясый, киңәш-табыш итмәкче була, ә анда канкоеш оештыралар, аңлашу килеп чыкмый. Тау ягының Мәскәүгә күчүе белән дә килешә алмый. Казанны яулап алыр алдыннан Казан ханлыгы икегә бүленә. Тау ягы инде Мәскәү күзәтүе астында була. Шаһгали өченче тапкыр тәхеткә утыргач, бер-ике атна да үтми, Мәскәүдән, шул мәсьәләне карау өчен, Казанга илчелек җибәрүләрен сорый. Рус патшасының Тау ягын үзенә кайтаруларын, һич булмаса, шул җирләрдә җыела торган салымны Казанга җибәрүләрен таләп итә. Илчелек, чыннан да, Казанда булып китә. Әмма Шаһгалинең бер генә үтенече дә канәгатьләндерелми. Рус хөкүмәте Казан ханын инде ул вакытта тизрәк Мәскәү наместнигына алыштырырга омтыла. Шулай итеп, 1552 елның февралендә Шаһгалине тәхеттән ваз кичәргә мәҗбүр итәләр. Минемчә, ул нинди нәселдән булганын бик яхшы аңлап, кайчандыр әби-бабалары буйсындырган дошманнарына хезмәт итәргә туры килгәненә ачынып яши. Нишлисең, бу – сәяси чынбарлык.

:: Шаһгали идарә иткән чорның Казанны «хәлдән тайдыру»да, соңыннан аны Россия составына кертүдә өлеше булганмы?

– Минемчә, андый өлеш бар, әмма Казан ханлыгының зур югалту кичерүендә бу – төп сәбәп түгел.

:: Шаһгалинең язмышы ничек булып бетә?

– Казанны руслар алганнан соң, Шаһгали Касыйм шәһәренә кайта һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда ханлык итә, Иван IV аңа Сөембикәне көчләп кияүгә бирә. 1557–1558 елларда Ливон сугышында катнаша. 1567 елда 61 яшендә вафат була. Сөембикәнең исә ире белән бернинди алыш-биреше булмый. Улы Үтәмешне чукындырганнар дигән хәбәрне ишеткәч, аның киләчәккә соңгы өмете сүнә. Яшәвенең мәгънәсе калмый. Соң чиккә җиткереп мәсхәрәләнгән Сөембикә күзгә күренеп сула, саргая, ашаудан кала һәм бу газапны кичерә алмыйча, 1557 елда дөнья белән хушлаша. Бу вакытта аңа бары тик 38 яшьләр тирәсе генә була. Татар тарихында дәүләт башлыгы булып торган бердәнбер хатын-кыз Сөембикә-ханбикә татар халкы хәтерендә бүгенгәчә каһарманлык, ватанпәрвәрлек, иманга тугрылык сыйфатларын чагылдыручы символ буларак кабул ителә. Аның турында легенда һәм риваятьләр, бәет һәм җырлар иҗат ителгән. Бу образ сәнгатьнең төрле өлкәләрендә иҗат итүче осталарны бүген дә илһамландыра.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ГӨЛНАРА ЭРКАЕВА:
«ҮЗЕМНЕКЕ ИТЕП ЯРАТСАМ ИДЕ, ДИП ТЕЛӘДЕМ»

Уйламыйча әйткән сүзнең чынга ашуы аның тормышын икегә бүлә. Парлы еллар һәм ялгызлык. Ике ятим баласын гына түгел, тагын бер үксез сабыйны да аякка бастырырлык көч таба ул үзендә. Балтач районының Арбор авылында яшәүче Гөлнара Эркаева язмышы күпләргә гыйбрәт булсын иде. Үзе белән сөйләшкәч, бер йөрәгенә күпме ярату, сабырлык сыйганына сокландым.

Әниемә һәйкәл куярлык!

Гөлнараның әнисе Нурания апаны да язмыш үзенчә сыный. Яшьлек юләрлеге белән ул авылга килгән үзбәк егетенә гашыйк була. Егетнең дә ниндие бит! Сабантуйларда төрле шөгыльләр күрсәтүче, циркта чыгыш ясаучы, биеклектәге баудан тотынмыйча йөрүче кеше. Андыйлар кемнең генә йөрәген яуламас! Егет Балтач кызы Нурانияне Үзбәкстанга алып китә.

– Алар матур гына яши башлыйлар. Әти әнигә карата начар булмаса да, өйдәге туганнары бик җәберлиләр үзен. Әмма әни түзә. Авыр тормышы хакында берәүгә дә сиздерми. Сабырлыгы сынгач, мине алып Татарстанга кайтып китә. Әтинең дә ялгыз каласы килми. Җаен таба. Артыннан кайта да мине урлап китә. Әни кабат Үзбәкстанга китәргә мәҗбүр була. Минем хакка дип кире әти янына кайта, – дип сөйли Гөлнара.

Ир белән хатынның аралары да якынаеп киткәндәй була. Нурания белән Рузунбайның икенче балалары Элморад туа. Тик яңадан бер-берене аңламау башлана, тавыш-гауга чыгып кына тора. Түземлеге беткәч, Нурания апа ике баласын ияртеп, тагын кайтып китә. Бу юлы инде ире дә эзләп кайтмый, үзе дә кире китми.

– Әни монда кайткач, икенче кат кияүгә чыкты. Нургаян абый белән бик матур яшәделәр. Ул безне какмады, сукмады. Безнең тагын ике туганыбыз: сеңлем Рания, энем Рәсүл бар. Һәркайсыбызның – үз тормышы. Нургаян абый да исән түгел инде, – ди ул.

Күңеле сизенде

Гөлнара да әнисе язмышын кабатлый. Чит милләт кешесенә кияүгә чыга. Әмма әнисеннән аермалы буларак, ул никахта бик бәхетле яши.

– Мин кечкенәдән тегәргә өйрәндем. Әбием тегүче иде. Мәктәпне бетергәч, Казанга укырга кердем. Аннан районга эшкә кайттым. Тик тегү эшен генә ташларга туры килде. Уйладык-уйладык та сеңлем белән Казанга чыгып китәргә булдык, – дип искә ала Гөлнара.

Кызлар бер кафега официант булып эшкә урнашалар. Булачак ире белән дә ул шунда таныша. Кыз эш урынын үзгәрткәч, Әкиф аны эзләп таба, аралаша башлыйлар.

Аларның яшь аермасы 22 ел була. Ул вакытта Гөлнарага – 26 яшь. Якыннарын, туганнарын Әкифнең башка милләттән булуы түгел, яшь аермасы күбрәк борчый.

– Берәү дә яхшы сүз әйтмәде. Әнием дә каршы иде. Мин исә үз язмышымны үзем сайладым. Әниемә: «Үз яшемдәге бер егеткә кияүгә чыкканчы, бу әфәндегә кияүгә чыгып, өч көн бәхетле яшәргә риза», – дидем. 3 көн түгел, 8 ел булды. Мин бары тик шуның кадәр генә бәхетле яшәп калдым. 34 яшемдә ике балалы тол хатын идем, – ди Гөлнара.

Әкиф белән Гөлнараның Сәмирә һәм Аяна исемле ике кызлары туа. Ир белән хатын бер-берсен аңлап яши. Җае чыкканда, Бакуга да баргалыйлар. 2010 елда Әкиф әфәндене гаиләсе белән үз ягына кайтып, кызының туган көнен уздырасы килә. Акча ягы да мактанырлык булмый. Башта Гөлнара каршы килә. Тик ире хакына ризалаша. Кызларының туган көненә Бакуга китәләр.

– Иремнең туганнары бик якын итеп каршы алды. Анда бер ай тордык. 27 декабрь көнне ирем иртән торды да, кирәк-яраклар алырга дип, кибеткә чыгарга җыена башлады. Безне тәм-томнар белән сыйламакчы. Иремнең әнисе дә безнең белән иде. Ирем чыгып барганда егылып китте. Шул егылудан башка тормады. Табиблар, тромбы өзелгән, диделәр. Ирем белән бардым, ирсез кайтып киттем, – ди Гөлнара. – Дөрес, ир туганнарым анда калуымны теләде. Ярдәм итәбез, фатир алып бирәбез, диделәр. Тик минем үз ягыма кайтасым килде. Мине бит монда Камиләм көтеп тора иде.

Камилә

Гөлнара Сәмирә белән бергә Камиләне дә имезеп үстерә. Сабыйны әнисе ташлап калдыргач, йөрәгә түзмичә барып ала ул аны. Алмас та иде – үз каны ага. Баланы ташлаган хатын-кыз энесеннән авырга кала.

– Энем яныма килде дә, апай, бер кыз миннән авырлы, баланы алып кайтмыйм, алдырам, дип әйтә, диде. Аборткa акча сорап алган, тик тотып бетергән, баланы төшертмәскә булган икән. Тагын энемне чакыртып, баланы табам, тик ташлап калдырам, дигән. Инде нишлим? Төн йокыларым качты. Бу хакта Әкифкә әйттем. Ул бик тыныч кеше иде. Сабыйны син алырга тиеш, энеңнең баласы бит, диде. Шуннан соң баланы барып алдым, – дип сөйли Гөлнара.

Камилә турында сөйләгәндә, ул елаудан туктамады. Дөрес, баштарак әлеге баланы кабул да итә алмый ул. Ни дисәң дә, үзеңнеке түгел бит инде. Әмма барыбер назын, яратуын бирергә тырыша. Кызы Сәмирәне ничә тапкыр үпсә, Камиләне дә шуның кадәр үбә. Аралары 7 генә ай була аларның. Үз баласына күкрәк сөте урынына ботка ашата, сөтен сеңлесенә имезә. Төннәрен исә бер теләк тели: «Раббым, бу баланы үземнеке итеп яраттырсаң иде!» Теләге кабул була. Гөлнара Камиләгә иялəшүен сизми дә кала. Тормышта төрле чаклар була. Әмма ул бирешми. Камиләне дә, Сәмирә белән Аянаны да кеше итәр өчен тырыша. Кызларны музыка мәктәбендә укыта. Камиләнең челтерәп аккан чишмәдәй тавышы югалмасын өчен, гел бәйгеләргә йөртә. «Йолдызлык» («Созвездие») бәйгеләрендә призлы урыннар яулый. Казаннан бүләккә бирелгән мутон тун киеп кайта.

Моннан ике ел элек Камиләне әтисе үз гаиләсенә ала. Гөлнарага аерылышу җиңел бирелми. Кешегә сиздермәскә тырышса да, ул сеңлесенә нык бәйләнгәнен аңлый. Камилә үз әнисенең кем икәнен дә белә. Хәер, тәмсез телләр тик тора аламы инде? Кечкенә чагында ук җанын яралап, син аларның кызы түгел, дип кайтаралар. Урамда ямьсез кыяфәттә йөргән әнисен дә күрсәтәләр. Сабый минем әни андый була алмый, дип гарьләнеп озак елый. Гөлнара әнисе урынын алырга теләми дә. Энесе баласы булгач, ул үзенә башта ук апа дияргә куша.

– Кайткан саен рәхмәт әйтә сабыем. Сәмирә, Аяна белән сөйләшеп сүзләре бетми. Мин аларны читтән генә күзәтергә ятатам. Аллаһы Тәгалә бәхетләрен бирсен иде, дип телим. Сәмирә быел 11не бетерә. Адвокат буласы килә. Документларын Баку уку йортына да тапшырырга җыена, – ди Гөлнара.

Әтисе туганнары… Бу хакта Гөлнара озак сөйли ала. Ул Әкифкә туганнары өчен бик рәхмәтле.

– Ирем мине гаиләсе алдында дөрес итеп куя белде. Сайлаган хатынымны кабул итүегезне сорыйм, сез аны яратырга тиеш, диде. Шул көннән бирле мин кадерле килен булдым. Ирем үлгәнгә – 11 ел. Аның туганнары мине 11 көнгә дә ялгыз калдырмады. Һәрвакыт ярдәм итеп торалар. Кайчакта алардан нидер сорарга да оялам. Әмма алар безне ташламый. Бертуганнары гына түгел, ике туганнарына кадәр ярдәм итеп тора, – ди Гөлнара. – Үземнең дә аларга биргән вәгъдәм бар. Әкифне җирләгәч, мин сезнең янга балаларым белән елга бер булса да килермен, дидем. Пандемия аркасында ике ел барганыбыз юк. Их, бер күрешеп, иремнең рухын сөендерәсе иде!

Әкифе күкләрдән карап сөенәдер, мөгаен. Иренең рухына тап төшермәгән, ике баланы кеше итәр өчен көнтөн тегү теккән, эштән курыкмаган Гөлнарасының догалары кабулдыр.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Игълан тактасы

Кемгә кирәк?

42–46 нчы үлчәмдәге бер дә киелмәгән җәйге күлмәк, кофта-чалбарлар бар.
Рузилә ГАРИПОВА

***

12–13 яшьлек кыз бала өчен җәйге киемнәр бар.
Ләйлә ВАФИНА

***

Яхшы хәлдәге, берничә тапкыр гына килгән 48 нче үлчәмдәге кышкы тун, 38 нче үлчәмдәге кышкы аяк киеме бирәм.
Гөлия ГАБИТОВА

***

Кулланышта булган бала караваты, өстәл белән шкаф бар. Кирәк кешеләр 89872076910 телефон номерына шалтыратсын иде.
АЙГӨЛ

Кемдә бар?

Авыл җирендә яшибез. Кызымның ике баласы бар. 5 яшьлек кыз балага, 10 яшьлек малайга киемнәр бирүче булмасмы?
ФӘРИДӘ

***

Берәр кешедә 11–12 яшьлек кыз балага яраклы кышкы киемнәр булмасмы икән? Алдан ук рәхмәтемне җиткерәм.
ЭЛЬВИРА

***

12–14 яшьлек ир бала өчен киемнәр кирәк.
ГӨЛШАТ

***

Авылыбызда авыр хәлдә яшәүче гаилә бар. Әниләре дә үлеп китте. Ике ир-ат ялгыз калдылар. Шуларга киемнәр кирәк иде. Аларның үлчәмнәрен дә сораштым. 48–50 нче үлчәм кияләр икән. Бу гаилә бер генә ярдәмнән дә баш тартмый. Бергәләп булышсак иде.
МИНСЫЛУ. Кукмара районы

***

Балалар өчен бер капчык йомшак уенчыклар бар. Кемгә кирәк, хәбәргә чыгыз.
ГӨЛФИЯ. Казан

Белдерүләр буенча редакциягә шалтыратсагыз иде. Элемтәгә керер өчен телефон: 222-09-67, 89872076910.

РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛА:

«БЕЗГӘ ҮЗЕБЕЗДӘН БАШКА БЕРКЕМ ДӘ ЯРДӘМ ИТМӘЯЧӘК»

Милли тормышта да, сәясәттә дә иң актив, кыю шәхесләрнең берсе Ркаил ЗӘЙДУЛЛА белән бу көннәрдә сөйләшер сүзләр шактый. Хәер, без генә түгел, яныннан кеше өзелеп тормый икән. Язучылар берлегенең кайнап торуы сөендерде, билгеле. Әңгәмәбез исә – республиканың киләчәге, язучының хәле, әдәби вазгыять турында барды.

:: Депутат һәм Язучылар берлеге рәисе буларак елны нинди кәеф белән тәмамлыйсыз? Нинди уңышлар булды, нәрсәләрне югалттык?

– Еш кына син уңыш дип уйлаган нәрсә уңышсызлык булып чыга. Иҗат мәсьәләсендә бу бигрәк тә шулай. Язучының гомере гел уңышсызлыклардан тора дисәң дә була. Ул һәрбер язган әсәрен камил дип уйлый, чынлыкта алай булып чыкмый. Еш кына иҗат кешесе текстыннан да, вазгыятьтән дә җиңелә. Иҗтимагый эшләргә килгәндә, без моны эшләдек, моңа ирештек дип мактанырлык нәрсәләр бик юк. Россия субъектларында гавами хакимият турында закон кабул ителгәч нәрсә дип мактанасың инде?.. Дөрес, Татарстан Дәүләт Советы аңа 100 процент каршы төште һәм үзенең төзәтмәләрен әзерләп җибәрде. Кызганыч, аларның берсе дә кабул ителмәде. Хәер, принципиаль булмаган бер пункт кабул ителде, ә төп мәсьәләләрдә безнең фикерне ишетмәделәр. Хәзер безгә мәгариф, сәламәтлек, финанс министрларын да Мәскәү билгеләячәк. Россия кәгазьдә федератив саналса да, де-факто унитар илгә әверелде. Шуңа күрә бу вазгыятьтә нинди дер уңышлар турында сөйләшеп утыру урынсыз булыр иде. Әлбәттә, Язучылар берлегендә күпмедер үзгәрешләр булды. Ләкин бит безнең төп миссия – әдәбиятны пропагандалау, язучыларга ярдәм итү. Бу инде иҗат кичәләре, очрашулар, башка әдәби чаралар үткәрү дә. Хәзерге шартларда анысы да – кыен эш. Әйтик, күптән түгел Марсель Галиевнең иҗат кичәсе булды, халык бик аз килде. Язучыларның туган яклары да халык белән очрашулар оештырырга ярдәм итә. Марсель Галиевнең, мәсәлән, Азнакайда да иҗат кичәсе булачак. Мөслим, Әлмәт, Баулы районнары да якташ язучыларына хәерхаһлы. Саный китсәң, андый районнар күп. Кайберәүләр Язучылар берлеге юбилей үткәрергә кирәк тә, җирләүдә башлап йөрүдә кирәк, дип әйтергә ярата. Минемчә, аларның икесе дә – бик зур эш. Берлекнең эшләре аның белән генә чикләнми, әлбәттә.

:: Татарстан Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе язучыларның абруен күтәрү йөзеннән әдәби конкурс игълан иткән иде. Күптән түгел аның җиңүчеләре билгеле булды. Конкурс нәтиҗәләреннән канәгатьме?

– Аның нәтиҗәләре шаккатырды. Беренчедән, объектив булды. Югыйсә өч номинациядә бер кеше җиңә алмас иде. Шул ук вакытта җиңә алмаган, төшеп калган өлкән язучыларның рәнҗүен дә аңлыйм мин. Моны, я әсәренең сыйфаты түбәнрәк булган дип аңларга кирәк, я жюриның зәвыгы бүтән төрлерәк.

Хәер, жюри бәясе бөтенләй үк объектив була алмый. Әсәр бит математика формуласы түгел. Кемгәдер ошаган әсәр икенче берәүгә ошамаска мөмкин. Аның берсе – романтик рухта, икенчесендә – кырыс реализм. Безнең әдәбиятта мәгърифәтчелек идеяләренә тарткан әсәрләр дә күп. Төрлесе бар. Ул шулай булырга тиеш тә.

Миңа конкурсның яңа исемнәр ачуы да ошады. Әйтик, повесть номинациясендә Әгерҗедән Наилә Харисова беренче урын алды. Ләкин ул бөтенләй үк билгесез кеше түгел. «Татар әдәбиятында нәрсә бар соң инде?» – дип әйтергә яраталар бит әле. Еш кына әдәбиятның бер гаебе дә булмый, бары тик нәрсә бар соң дигән кеше бернәрсә дә укымаган була. Бу очракта да шулай. Ул авторны ишетмәвем аның гаебе түгел, минем гаеп, әсәрләрен мин укымаганмын. Авыл хуҗалыгы министрлыгы үткәргән конкурста ул җиңгән дә булган икән. Киң даирә укучыга билгеле булмаган авторларның килеп чыгуы шулай ук бу конкурсның кирәклеген күрсәтә.

Мондый ярышлар авторларны язарга рухландыра да бит әле ул. Язучы яза икән, яшьләргә матди ярдәме дә була.

Роберт Миңнуллин исемендәге конкурсның да әһәмияте зур. Дөрес, аны да псевдонимнар белән үткәрергә кирәк булгандыр. Анда китапханәчеләр, шәхси нәшрият, «Татмедиа» вәкилләре белән берлектә жюрида идем. Алар белән миңа кыенрак булды. Мин әсәр әйбәт дип уйлыйм, алар бүтәннәрне атыйлар.

:: Кайсы жанр үсештә, кайсы торгынлыкта?

– Шигърият традицион рәвештә алда. Ул безнең Шәрык халкы икәнлегебезне күрсәтә. Әлбәттә, башка халыкларга танылыр өчен прозаның алда булуы кирәк. Ник дигәндә, шигырьне тәрҗемә итү кыен. Тәрҗемәче автор кимәлендәге иҗат кешесе булмаса, тәрҗемә итү мөмкин дә түгелдер әле. Прозаны исә тәрҗемә итү читен түгел. Толстой: «Проза әсәрен бүтән телгә тәрҗемә иткәндә аның кыйммәте күренә», – дигән. Кибәкләре коелып кала, асылы чыга. Бу сүздә хаклык бар, әлбәттә. Әмма безнең прозага карата сораулар бик күп. Мәсәлән, Роберт Миңнуллин исемендәге конкурска мин скетч номинациясен тәкъдим иттем. Очрашуларда укытучылар әнә шул жанрны сорый. Кызганыч, скетчлар бик аз булды һәм булганнары да бик уңышлы түгел. Аның традициясе өзелгәнме, башка сәбәпләре дә бармы – әйтеп булмый. Шуңа күрә беренче-икенче урынга лаеклы әсәрләр табылмады. Безнең бит төп максат мәктәпләр өчен драма әсәрләре яздыру иде. Игътибар кимегәч, язмый башлыйлар. Язмагач, традицияләре дә онытыла. Шуңа күрә бу конкурслар күз уңыннан читтә калган жанрларда иҗат итәргә дә этәргеч бирер дип уйлыйм.

:: Ярый, конкурсларның нәтиҗәләре дә әйбәт, әсәрләр дә языла башлады ди, укучысы бармы соң?

– Мәктәпләрдән татар теле кысрыклап чыгарылгач, укучысы кими икән, язучысы да сирәгәя. Язучы укучылар арасыннан үсеп чыга.

Язучылар авыллардан чыга иде. Бездә генә түгел, бөтен җирдә шулай. «Шагыйрьләр авылда туа, Парижда үлә» дигән әйтем дә бар бит. Авыллар да хәзер, беренчедән, балалар бик аз, икенчедән, алар үзара урысча сөйләшә. Җәй көне Оренбург өлкәсенең атаклы Каргалы авылында булдык. Анда мәктәп директоры балаларның мәктәпкә килгәндә урысча белүен таләп иткәнгә, балалар бакчасыннан ук урысча тәрбиялиләр. Ул мәктәптә исем өчен бәлки бер-ике татар теле дәресе керәдер дә, әмма андый мөнәсәбәт булганда, ул дәресләрдән нәтиҗә көтү файдасыз. Шуңа күрә анда татар үзәге оештырганнар. Дәрестән соң балалар шунда килеп дин сабаклары ала, кул эшләренә өйрәнә, сабаклар татар телендә бара.

:: Сөйләм телен үзләштерсәләр дә, китап укырлык булып җитешми инде андый үзәкләрдә балалар...

– Анысы шулай. Юкса бит мәгърифәт үзәге булган Каргалы авылы бу. Шулай да, химаячеләрнең телне саклауда дәүләткә ышанып ятарга кирәкми, бабайлар заманындагы кебек үзебезгә калды дип, катгый торулары өмет уята.

> Халык бит ул кеше кебек. Кешенең дә үләсе килми, көрәшә, иммунитет булдыра. Халыкның да юкка чыгасы килмәс, каршылыгы булмыйча калмас, дип уйлыйм мин. Әрмән шагыйре Геворг Эмин: «Безне шулкадәр кыстылар ки, без алмазга әверелдек», – дигән бит әле, аны татарга карата да әйтеп була.

:: Җанисәпкә карата фаразларыгыз нинди?

– Башкортстан һәм башка төбәкләрдәге вазгыятьне исәпкә алсак, татар кимеячәк, әлбәттә. Беренчедән, демографик күрсәткечләр түбән. Безнең татар бүтән төрки халыклар кебек күп бала тапмый. Гаиләләрдә уртача бер, ике бала. Халык бераз артсын өчен генә дә гаиләдә кимендә өч бала булу кирәк. Икенчедән, урыслашу бик көчле. Моңа инану өчен телевизорны ачу да җитә. Анда Анастасия Насыйбуллина, Анна Кәримова, Владислав Шакиров кебек исем-фамилияләр очрый. Фамилияләре татарча булса да, асылда татар түгел инде алар. Без ассимиляцияләшү аркасында бик кимедек. Башкортстанда ырыларга бүлү дә санны киметүдә үз ролен уйнаячак. Фальсификацияне каплау өчен уңайлы сылтау инде бу. Хәзер менә без аларга аңлаттык һәм алар үзләренең башкорт булуларына төшенделәр, дип әйтергә була.

Җанисәптә 100 меңгә кимесәк тә, безнең өчен ул – бик зур сан. Чөнки без 150 миллионлы халык түгел. Дамир Исхаков, үзебез җанисәп үткәрик, ди. Ләкин бит хикмәт санда түгел, халыкның асылында, сыйфатында. Безнең үзәгебез көпшәкләнде. Умыртка сөяге нык булса, милләт барыбер юкка чыкмый, форсат туугa ул яңадан кабынып китәргә, терелергә мөмкин. Шуның өчен оеткыны саклап калырга кирәк. Мәгариф системасы бу хәлдә булганда, анысы да бик читен. Кызганыч, без Октябрь инкыйлабына кадәрге бер йодрыкка тупланган милләт түгел.

:: Сан югалту халыкка тагын бер һөҗүм кебек тәэсир итәчәкме?

– Советлар иле вакытында без сан ягыннан руслар, украиннар, белоруслардан соң, үзбәкләр белән бер чамадарак булганбыз. Хәзер үзбәкләр – 30 миллион, без һаман шул чама. Дагыстаннар, чеченнәр сан ягыннан артты. Рус халкы – 130 миллион, татарлар – 5 миллион. Аерма бик зур, билгеле. Әлбәттә ассимиляция гасырлар буена барган. Урысны тырнап карасаң, татар килеп чыга дигән әйтем тикмәгә генә килеп чыкмаган бит инде. Дәүләт токкан халык бүтән халыкларны йотарга тырыша. Бу – табигый. Дөрес, Европа илләрендә аз санлы халыкларга үзләрен сакларга бөтен мөмкинлекләр бирелә. Мәсәлән, Англиядә кельт теленә игътибар зур. Германиядә дә аз санлы халыкларга бөтен мөмкинлекләр бар. Аз санлы халыкларның үсеш алуы, аларның әдәбиятлары, сәнгатьләре үсүе, милли-мәдәни ихтыяҗлары канәгатьләндерелүе Россиянең иминлегенә кур-

кыныч тудырмый дип уйлыйм мин. Президент атамасы белән дә шул ук хәл. Президент атамасы, беренчедән, татар сүзе дә, рус сүзе дә түгел, латиннан кергән, алда утыручы дигәнне аңлата. Футбол берләшмәләре президентлары бар, Фәннәр академиясенең, пэн-клубның президенты бар. Алайса ул сүзне гомумән тыйсыннар. Татарстан Президенты белән Россиянекен беркем дә бутамый бит инде. Республика башлыгы ничек аталса да, ризасызлык тудырмаска тиеш иде кебек. Унитарлаштырырга тырышуның бер чагылышы инде бу. Киләчәктә Татарстан дотацион республика булып калырга мөмкин.

> Татарга татардан башка беркем дә ярдәм итмәячәк. Без бары тик үзебезгә генә таяна алабыз.

:: Гаиләдәме төп өмет?

– Кызганычка, безнең милли үзаңыбыз бик түбән. Аны гаиләдә генә тәрбияләп була. Менә мин бер әрмән гаиләсен беләм. Казанда әрмәнчә мәктәп тә юк бит, ә балалары кечкенәдән үз тарихларын белә, туган телләрендә чатнатып сөйләшә. Без яшәгән йортта таҗик гаиләсе дә бар. Җиде-сигез бала ишегалдында үз телләрендә сөйләшеп, уйнап, әвәрә киләләр иде. Бу йортта ипотекага фатир алган гаиләләр бик күп, шуларның туксан проценты – татарлар. Янәшәгә балалар бакчасы салганчы, ишегалдында бөтен балалар татарча сөйләшә иде. Шул ассимиляция фабрикасын салып куйдылар да, хәзер инде бөтенесе урысча гына сөйләшә. Гаҗәп инде ул, ишектән татар баласы кереп китә, урыс булып килеп чыга. Әле бит аның тәрбиячеләре дә татар! Күрсәтмә бирелгән, күрәсең. Хәер, безгә күрсәтмә дә кирәкми. Бигрәк тә хатын-кызлар бу мәсьәләдә меркантиль. Ике авыл хатыны очрашса, үзара урысча сөйләшә. Урысча белсәм, әллә кем булам дип уйлыйдыр инде. Алай булса, бөтен урыс әллә кем булган булыр иде. Наданлык, үз тарихыңны белмәү фаҗигасе инде бу.

Шулай да, бөтенләй үк төшенкелеккә бирелергә ярамый. Җитмешенче, сиксәненче елларда бөтенләй өмет юк сыман иде. Хәзер ниндидер алгарыш бар. Булганны күрә белергә дә кирәк.

:: «Яшьләр әдәбиятка киләме?» – дип сорагач, сез гадәттә, Йолдыз, Рүзәл, Рөстәмнәрне санап китәсез. Алардан соң килүчеләр бармы?

– Яшьләр бар. Аларның күбесе кызлар, егетләр юк. Аннан соң мин аларның стильләрен дә бик аңлап бетерә алмыйм. Шигырьдә язмыш юк, метафоралар, әллә нәрсәләр. Миңа калса, үзләре нәрсә язганны бераз вакыт узгач үзләре дә аңлап бетерә алмыйлардыр.

> Әдәбиятның киләчәге булсын өчен, 20 яшьлек егетләр килергә тиеш. Әдәбиятның тарихын карасаң, егерме ел саен кан алмашкан. Рүзәлләрдән соң егерме ел үтмәде әле. Мин инде шуңа өметләнеп торам.

:: Әдәбиятта ел язучысы дип кемне атар идегез?

– Аерып әйтә алмыйм. Ярамыйдыр да.

:: Тормышыгызда елның иң шау-шулы вакыйгасы нинди булды?

– Минем тормышны Язучылар корылтаенда җитәкче булып сайлану борып җибәрде. Элекке эш режимын үзгәртте, иҗатка вакыт та бик калмады. Киң полотнолы проза әсәрләре язарга исәп бар иде. Кол Шәриф романын тәмамларга, Ильяс Алкин әсәрен киңәйтеп эшләргә кирәк иде. Алар үз вакыты җиткәнне көтеп ята. Кешеләр белән аралашу арыта. Төрлесе бар бит. Күзеңә карап тәнкыйть итсәләр бер хәл, арттан сөйләүчеләр, әләк бирүчеләре дә бар. Алынгансың икән бу эшкә, ахыргача тартырга кирәк. Ә язучылар миңа барысы да бертигез. Бу – якын дустым, дип аерып әйтеп тә булмый. Өлкәнәйгән саен якын дуслар сирәгәя, әле кала микән? Әйбәт әсәр яза икән, минем өчен дә куаныч ул. Чөнки мин әдәбиятка очраклы килеп кергән кеше түгел, шуңа татар әдәбиятының мөкәммәл булуын, бүтән халыкларга да тәрҗемә итәрлек әсәр тууын телим.

:: Иң зур теләгегез?

– Язучы Марсель Галиев: «Авыр заманда яшибез дигәнне туганнан бирле ишетәм инде», – ди. Чыннан да шулай. Катлаулы булмаган еллар килерме – анысын әйтеп булмый. Бу илдә ул килмәскә дә мөмкин. Тормыш бит ул үзе катлаулы. Аны шулай кабул итәргә кирәк тә. Туганбыз икән, без – яшәргә хөкем ителгәннәр. Шуңа күрә төшенкелеккә бирелмик, ә иң мөһиме – үзебез булып калыйк, асылыбызны югалтмыйк.

Әңгәмәдәш –
Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Язып кына карыйм

БАШСЫЗ КЕШЕ ЯЗМАЛАРЫ

< Дәвамы. Башы 26 ноябрь, 10 декабрь саннарында

Чикләнгәнлек

Монда иң үзәкне өзгән нәрсә – чикләнгәнлек. Ул һава җитмәү белән башлана. Син күкрәк тутырып сулыш ала алмыйсың. Монысы чынбарлыкта да, образлы итеп әйтәм дисәң дә, шулай. Бүлмәдә дә һава җитеп бетми. Форточка ачып булмый, үпкә чирлеләр алай итә алмый бит инде. Ачсаң да җитми ул. Кемнең – 25, кемнең 50–70 процент үпкәсе зарарланган. Барыбыз да кислород маскасында.

Коридорга чыгып йөреп керәсең. Ул кыска. Бүтән этажларга төшеп төртенеп йөрү мөмкинлеге юк, йогышлы авырулар бит инде без – чир таратудан сакланырга тиешбез. Урамга да чыгарга ярамый. Безгә беркая барырга ярамый. Барасы да килми. Дөресрәге, хәл юк. Без – бер палатадагы кешеләр артык сөйләшмибез дә. Үзара да, хәтта телефон аша да сөйләшәсе килми. Ятып ялыккач, коридордан урап керәбез. Монда тиз ялкыта. Аптырагач, тәрәзәгә капланган булабыз.

Ковид – индивидуаль чир. Уртак яклары булса да, һәркемдә үзенчә чагылыш таба. Ул әле үзен сиздерә башлау белән үк кешенең элекке чирләрен кабызып җибәрә. Башың авыртулы икән – башыңны сызлата, эчке әгъзаларыңда чирең бар икән, шуларны авырттыра. Нинди чирең бар, бөтенесе дә баш калкыта.

Мин диеталар тота-тота, физик күнегүләр ясый-ясый, катгый режимга күчеп, кандагы шикәрне тугызга кадәр төшергән идем инде. Бу зәхмәткә юлыккач, ул тагын утыз дүрткә җитте. Шикәр чирен элек «бирән зәхмәте» дип йөрткәннәр бугай. Дөрес эшләгәннәр. Монда килеп эләккәч, мин дә туймас тамакка әйләндем. Моңа уколлар сәбәпче, диләр. Ниндидер гормоннар кадыйлар, шулар һәрвакыт ачыгу тойгысы уятып тора икән. Плюс шикәр чире. Боларның икесе бергә кушылгач, мин берүзем ике бирән кебек. Күпме ашасаң да, тамак туймый. Затлы-татлы ризыклар янында да ачтан интегергә мөмкин икән.

Ә шикәр күтәрелә. Монысы да ковид шикелләрәк мәкерле чир инде аның, моңа кадәр булган бөтен авыруларыңны уятып, көчәйтеп җибәрә. Минем дә бөтен тән сызлый, буыннар авырта. Яшьрәк чакта каратист булабыз дип, белер-белмәс көйгә, ком тутырылган капчык төеп, кулларны чыныктыра, кирпечтәр, штакетниктыр сындыра торган идек. Безнең кирпеч ваткан чакны берәрсе хәтерли микән, ә хәзер менә кул кырыйлары, бармаклар оеп җәфалый, сызлый, энәләр белән чәнечкән кебек була. Бөтен тән авыр, үзем дә хәзер ком тутырылган капчык шикелле. Буыннар тотмый. Ятсаң, тынычына ятып булмый, күңел тынгысызлана. Торып йөрим дисәң, хәл юк – исерек кеше кебек кылдыйн-былдыйн килеп атлыйсың. Берәрсе белән сөйләшәм дисәң, тел көрмәлә. Беркем белән дә сөйләшәсе килми. Аң йөгерек түгел, шуңа күрә сөйләшү дә эш кебек тоела.

Эндокринолог инсулинга күчәргә кыстый, мин карышам. Моңа кадәр таблеткалар белән дә шикәрне төшерә ала идем, бу чир генә узсын, тагын төшерермен, дим. Ул үзенекен итә, дәлилләр китерә. «Таблеткаларда торсаң, әкренләп бөерең эштән чыгачак. Ябыгуың да шуннан синең, бернинди дә рак нәтиҗәсе түгел бу», – ди. «Мондый шикәр белән комага китүең дә бар. Ник син үз-үзеңне кайгырта белмисең?» – дип тиргәп тә ала. Инсулинга күчү позицияләрне бирү шикелләрәк тоелса да, мин ризалашам. Чынлап та хәл бераз җиңеләя. Чагыштырмача инде.

Ә акыл эшчәнлеге, фикер йөртү сәләте һаман шул килеш. Мин укырга тырышам. Керми. Кайвакыт бер үк абзацны әллә ничә тапкыр укып чыгасың, сүзләре ятланып бетә. Ә фикере аңлашылмый. Бераздан ятланган сүзләрең дә онытыла. Бу бер мәгънәсез шөгыль кебек тоела. Тик мин алай түгеллеген яхшы беләм. Акылны әледән-әле күнектереп торырга, эшләргә мәҗбүр итәргә кирәк. Бу үзенә күрә физик күнекмәләр кебек нәрсә. Мин төшкә кадәр вакытымны шундый шөгыльләргә бүлгәләп куям. Болай эшләргә мине курку хисе мәҗбүр итә.

Фикер йөртү рәвешенә, хисләргә йогынты ясагач, ковид күпмедер дәрәҗәдә психик авырудыр кебек тә тоелып китә. «Осложнение» ди бит инде халык. Әгәр аннан соң әнә шул осложнение калып, фикерләр һәм хисләр үткенлегенә тәэсир итсә? Йөгерек фикерли алмый торган аңгыралар җәмгыятенә әйләнмәбезме? Хиссез, кичерешсез кешеләргә? Без дип уйласам да, мин иң беренче чиратта үземне күз уңында тотам инде. Үзем өчен куркам. Һәм барысын да үз мөмкинлекләремнән чыгып башкарырга тырышам.

Ә көн тәртибе болайрак. Иртәнге аштан, төрле процедуралардан соң бер сәгать укырга. Җиңел түгел. Башка керми, текәлеп утырудан күзләр тонып бетә. Һәм мин һәр җөмләнең, һәр абзацның мәгънәсен сыгып алырга тырышам. Кайчагында язып та барам. Озакка сузыла, ләкин килеп чыга. Бераздан укыганны аңлау тизлеге арта төшкәндәй була. Һәрхәлдә, хәзер инде язып бару кирәкми.

Бераз ял иткәннән соң, мин язу эшенә тотынам. Минем беркайчан да нәрсә язарга дип баш ватканым булмады. Идеяләр һәрвакыт бар. Иде. Ә менә хәзер берсенә дә тотынып булмый. Кайбер әсәрләрнең хәтта җентекләп төзеп куелган планы да бар – язарга вакыт җитмәгәндә мин шулай да итәм. Онытылмый, соңыннан язарга да җиңелрәк була. Кыскасы, нәрсә язарга икәнен дә, ничек язарга икәнен дә яхшы беләсең. Ә язып булмый.

Нәрсәдән булса да башларга кирәк. Башлыйм. Ул хәтсез вакыт сөрлегеп сөйрәлә дә үзеннән-үзе сүтелеп китә. Билгеле бер күләмгә җиткәч туктыйм. Бераздан нәрсә язылды икән дип укып карыйм. Минем дәрәҗә түгел. Җуеп ташлыйм. Бернинди югалту тойгысы да юк. Чын әсәр түгел бит инде болар, фикер чарлау күнекмәләре генә.

Болай кыланучы бер мин генә түгел. Әнә, күрше караваттагы ир кроссворд чишеп ята. Рәхәт юлын тапкан. Бөтенесен бездән сорый, үзе язып кына бара. Алай да торым-торымга сүгенеп ала. Сүзләрен язганда хата җибәрә икән…

Без чикләнгәнлек эчендә яшибез. Сулар һавабыз да, уйларыбыз да, хисләребез дә чикләнгән. Тик һәр мизгелебез шул чикләрне киңәйтергә, читлекләрне ватарга тырышудан тора.

Дәвамы киләсе саннарда >

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ ПО СОГЛАСОВАНИЮ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦЫ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Дерябиной Марией Владимировной (420111, РФ, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Ташаяк, 2а, 13б, mrczeo@mail.ru, +7-987-215-01-46), выполняются кадастровые работы по уточнению земельного участка с кадастровым N 16:16:000000:9398, расположенного по адресу: РФ, Республика Татарстан, район Высокогорский, деревня Ивановка, СНТ «Каменка», участок №171.

Заказчиком кадастровых работ является Бурова Клавдия Васильевна (РТ, г. Казань, ул. Лукина, д. 11, корп. 1 кв. 80. Тел: +79503266272).

Смежный земельный участок, с правообладателем которого требуется согласовать местоположение границ: N 16:16:321201:1299 РФ, Республика Татарстан, район Высокогорский, деревня Ивановка, СНТ «Каменка», участок №174.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границы состоится по адресу: 420111, РФ, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Ташаяк, 2а, 13б 23 декабря 2021 г. в 11 часов 00 минут.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: 420111, РФ, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Ташаяк, 2а, 13б.

Требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 23 декабря 2021 г. по 24 января 2022 г., обоснованные возражения о местоположении границ земельных участков после ознакомления с проектом межевого плана принимаются с 23 декабря 2021 г. по 24 января 2022 г. по адресу: 420111, РФ, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Ташаяк, 2а, 13б.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24.07.2007 г. № 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

Җиңүче җирәбә юлы белән ачыкланачак.
Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, җирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

- ✓ мини-тракторлар;
- ✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
- ✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Совет урамы, 42А.

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 **ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ**

2 **ОНЛАЙН:** **vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.**

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 атнага бер, җомга килә	**465 сум**	**П2409** Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә	**1000,92 сум**

Реклама 16+

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru



Рәис Габдулла

10 декабрь санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: бөркет, терсәк, шом, Рюмин, кысан, чуар, Нәҗип, Лут, аренда, Чауш, Кабак, Ниш, кабат, тукан, Рә, Укчы, куб, аучы. **Вертикаль буенча:** ачалак, өлеш, ашу, Рока, тюбик, кысмыр, ана, Марк, Ника, тукран, юнәлеш, Аруба, Нурбәк, Илиада, чәч, ачыткы.

ВИКТОРИНА

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 **Биләү янындагы сугыш ничәнче елларда була?**
А) 1437 ел;
Б) 1812 ел;
В) 1312 ел.

2 **Ислам диненә ... пәйгамбәр нигез сала.**
А) Ибраһим;
Б) Мөхәммәд;
В) Муса.

3 **«Кара халыкны кара эштән аермас өчен, аларны укый-язарга өйрәтү һич тә кирәк түгел». Бу – кайсы патшаның указындагы сүзләр?**
А) Ярослав Мудрый;
Б) Петр I;
В) Анна Иоанновна.

4 **Юха ул – ...**
А) Казан федераль университетындагы музей;
Б) төрле кыяфәтләргә керә ала торган явыз рух;
В) монументаль сәнгать төре.

Җаваплар: 1) А; 2) Б; 3) В; 4) Б.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 17167 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 384

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+